© Изге Китапны тәрҗемә итү институты, 2007

# Левиләр

*Тулаем яндыру корбаны*

# 1

1 Раббы Мусаны чакырып алды да Изге чатырдан* аңа болай
диде:
2 – Исраиллеләргә игълан ит: «Кем дә булса берәү Раббыга
корбан китерсә, аның корбанлыгы эре яки вак терлек булсын.
3 Әгәр тулаем яндыру корбаны эре терлектән булса, ул кимче-
лексез ата терлек булырга тиеш. Корбан Раббы тарафыннан кабул
ителсен өчен, корбан китерүче кеше аны Изге чатырга керү урыны
алдына китерсен 4 һәм кулын тулаем яндыру корбанының башына
куйсын; нәтиҗәдә, Раббы корбанны кабул итеп, шул кешенең гө-
наһларын йолыр. 5 Үгезен ул Раббы алдында чалсын; ә Һарунның
угыллары – руханилар – корбан канын алып, Изге чатырга керү
урыны янындагы мәзбәхнең* һәр ягына чәчрәтсеннәр. 6 Корбан
китерүче кеше үзенең корбанының тиресен тунап, аны кисәкләргә
бүлсен. 7 Һарунның угыллары – руханилар – мәзбәхкә әйбәтләп
утын өйсеннәр дә ут кабызып җибәрсеннәр. 8 Алар үгезнең бүлгә-
ләнгән кисәкләрен, башын һәм маен мәзбәхтәге утыннар өстенә
тезеп куйсыннар. 9 Корбан китерүче үз корбанының эчке әгъзала-
рын һәм аякларын су белән югач, рухани аларны мәзбәхтә яндыр-
сын. Бу – тулаем яндыру корбаны, яндыру бүләге; ул Раббы ал-
дында хуш ис чыгарыр.
10 Әгәр тулаем яндыру корбаны вак терлек – сарык яки кәҗә икән,
ул кимчелексез ата хайван булырга тиеш. 11 Корбан китерүче үзе-
нең хайванын мәзбәхнең төньяк ягыннан Раббы алдында чалсын;
ә Һарунның угыллары – руханилар – аның канын мәзбәхнең һәр

---

* 1:1 *Изге чатыр* – исраиллеләр шушы чатырда Аллаһыга табынганнар. Чатыр эчендә ике бүлмә булган: Изге бүлмә һәм Иң изге бүлмә (карагыз: «Чыгыш» китабы 25:8; 26:1-35).

* 1:5 *Мәзбәх* – корбан китерү өчен махсус өстәл (карагыз: «Чыгыш» китабы 27:1-8).

ягына чәчрәтсеннәр. [12] Кеше үз корбанын кисәкләргә бүлгәләсен.
Шуннан соң рухани аның кисәкләрен, башын һәм маен мәзбәхтәге
утыннар өстенә өеп куйсын. [13] Кеше үз корбанының эчке әгъзала-
рын һәм аякларын су белән юганнан соң, рухани аларның һәммә-
сен мәзбәхтә яндырсын. Бу – тулаем яндыру корбаны, яндыру бү-
ләге; ул Раббы алдында хуш ис чыгарыр.

[14] Әгәр инде тулаем яндыру корбаны кош икән, Раббыга урман
күгәрчене яки бала күгәрчен китерелергә тиеш. [15] Рухани аны мәз-
бәхкә алып килеп, башын өзеп, аны утта яндырсын, ә канын
мәзбәхнең һәр ягына агызсын. [16] Аның бүксәсен аерып алып, мәз-
бәхнең көнчыгыш ягыннан көл сала торган урынга ташласын. [17] Ка-
натларын сындырсын, ләкин сындырып аермасын һәм мәзбәхтәге
утын өстендә яндырсын. Бу – тулаем яндыру корбаны, яндыру бү-
ләге; ул Раббы алдында хуш ис чыгарыр».

*Икмәк бүләге*

**2** [1] «Кем дә булса Раббыга икмәк бүләге китерергә тели икән,
аның бүләге иң яхшы бодай оны булсын. Онга зәйтүн мае
салынсын һәм хуш исле сумала* куелсын. [2] Аны Һарунның
угылларына – руханиларга – китерсен. Рухани учын тутырып он
һәм майны, бөтен хуш исле сумаланы алып, бу өлеш барлык бү-
ләкнең бер өлеше буларак, аны мәзбәхтә яндырсын. Бу – яндыру
бүләге; ул Раббы алдында хуш ис чыгарыр. [3] Ә инде икмәк бүләге-
нең артып калганы Һарун һәм аның угылларына булсын. Бу –
Раббыга багышлап яндыру бүләгенең тулысынча изге өлеше.

[4] Әгәр мичтә пешерелгән икмәк бүләген китерәсең икән, ул иң
яхшы бодай онынннан пешерелеп, зәйтүн мае кушылган төче кү-
мәч яисә зәйтүн мае белән майланган юка төче көлчә булсын.

[5] Әгәр бүләгең табада пешерелгән булса, ул иң яхшы бодай онын-
нан пешерелеп, зәйтүн мае кушылган төче икмәк булсын. [6] Аны
вакла да өстенә май сал. Бу – икмәк бүләге.

[7] Әгәр икмәк бүләге чүлмәктә пешерелгән булса, ул зәйтүн мае
белән иң яхшы бодай онынннан пешерелсен. [8] Шулай итеп әзер-
ләнгән икмәк бүләген Раббыга китер, аны руханига тәкъдим ит.
Рухани аны мәзбәхкә китереп, [9] аның бер өлешен алсын. Бу өлеш
барлык бүләкнең бер өлеше буларак, рухани аны мәзбәхтә яндыр-
сын. Бу – яндыру бүләге; ул Раббы алдында хуш ис чыгарыр. [10] Ә
икмәк бүләгенең калган өлеше Һарун һәм аның угылларына булыр.
Бу – Раббыга багышлап яндыру бүләгенең тулысынча изге өлеше.

[11] Раббыга китерелә торган бер генә икмәк бүләген дә чүпрә ку-
шып пешермә, чөнки Раббыга багышлап яндырыла торган бүләктә
чүпрә дә, бал да булырга тиеш түгел. [12] Раббыга боларны беренче

---

* [2:1] *Хуш исле сумала* – гыйбадәт кылганда яндырыла торган сумала.

уңыш бүләге итеп китерергә мөмкин, әмма, бүләк хуш исен чыгарырлык итеп, аларны мәзбәхтә яндырырга ярамый. [13] Үзеңнең барлык икмәк бүләкләреңне тозла, чөнки тоз – Аллаһы белән синең арада төзелгән килешүнең билгесе. Шуңа күрә тозсыз икмәк бүләген тәкъдим итмә, һәр бүләгең белән бергә тоз да китер.

[14] Беренче уңышларыңнан Раббыга икмәк бүләге китерәсең икән, аны беренче башаклардан китер, ул ашлык бөртеге кыздырылган, төелгән булсын. [15] Аның өстенә зәйтүн мае сал, хуш исле сумала куй; менә бу – икмәк бүләге. [16] Рухани исә бөртекнең һәм майның бер өлешен алсын. Бу өлешне, барлык бүләкнең бер өлеше буларак, бөтен хуш исле сумала белән бергә яндырсын. Бу – Раббыга багышлап яндыру бүләге».

*Татулык корбаны*

**3** [1] «Кем дә булса берәү Раббы алдына татулык корбаны китерә
икән, ул кимчелексез ата яки ана эре терлек булырга тиеш.
[2] Корбан китерүче, кулын корбанының башына куеп, аны
Изге чатырга керү урыны алдында чалсын; ә Һарунның угыллары – руханилар – аның канын мәзбәхнең һәр ягына чәчрәтсеннәр.
[3-4] Ул, Раббыга багышлап яндыру бүләге итеп, үзенең татулык корбаныннан эчке әгъзаларын каплаган бөтен эч маен, ике бөерен, бөер өстендәге, шулай ук биле янындагы маен һәм бавыр астындагы өлешен аерып алсын. [5] Һарунның угыллары аларны мәзбәхтәге утта тулаем яндыру корбаны өстендә яндырсыннар. Бу – яндыру бүләге; ул Раббы алдында хуш ис чыгарыр.

[6] Әгәр кем дә булса берәү татулык корбаны итеп Раббыга вак терлек бүләк итә икән, ул кимчелексез ата яки ана терлек булырга тиеш. [7] Әгәр кеше корбан итеп сарык китерә икән, аны Раббы алдында тәкъдим итсен. [8] Кулын корбанының башына куеп, аны Изге чатыр алдында чалсын; ә Һарунның угыллары аның канын мәзбәхнең һәр ягына чәчрәтсеннәр. [9-10] Корбан китерүче, Раббыга багышлап яндыру бүләге итеп, үзенең татулык корбанының симез койрыгын сыртыннан кисеп алып, маен, эчке әгъзаларын каплаган бөтен эч маен, ике бөерен, бөер өстендәге, шулай ук биле янындагы маен һәм бавыр астындагы өлешен аерып алсын. [11] Рухани аларны, ризык итеп, мәзбәхтә яндырсын. Бу – Раббыга багышлап яндыру бүләге.

[12] Әгәр дә кеше корбан итеп кәҗә китерсә, аны Раббы алдында тәкъдим итсен. [13] Кулын корбанының башына куйсын да аны Изге чатыр алдында чалсын; ә Һарунның угыллары аның канын мәзбәхнең һәр ягына чәчрәтсеннәр. [14-15] Корбан китерүче, Раббыга багышлап яндыру бүләге итеп, корбанының эчке әгъзаларын каплаган бөтен эч маен, ике бөерен, бөер өстендәге, шулай ук биле янындагы маен һәм бавыр астындагы өлешен аерып алсын. [16] Рухани аларны, ризык итеп, мәзбәхтә яндырсын. Бу – яндыру бүләге; ул хуш ис

чыгарыр. Бөтен май – Раббыныкы. [17] Бу – алар кайда гына яшәсәләр дә, сезнең киләчәк буыннарыгыз үтәргә тиешле мәңгелек кагыйдә: бернинди эч маен да, һичнинди кан да ашамагыз».

*Гөнаһ йолу корбаны*

**4** [1] Раббы Мусага болай диде:
[2] – Исраиллеләргә игълан ит: «Кем дә кем, ниятләмичә, гөнаһ кылса – Раббының боерыгына каршы килүче берәр эш эшләсә, ул түбәндәгеләрне башкарырга тиеш.

[3] Әгәр Баш рухани, гөнаһ кылып, халыкны гаепле итсә, үз гөнаһы өчен, гөнаһ йолу корбаны итеп, Раббыга кимчелексез үгез бозау китерергә тиеш. [4] Үгез бозауны ул Изге чатырга керү урыны алдына Раббы каршына китерсен һәм, кулын үгез бозауның башына куеп, аны Раббы алдында чалсын. [5] Баш рухани корбанның берникадәр канын алып, аны Изге чатыр эченә китерсен. [6] Бармагын канга манчып, Раббы каршында Изге чатыр эчендәге пәрдә алдында канны җиде тапкыр сипсен. [7] Аннары үгез бозауның берникадәр канын Изге чатыр эчендә булган Раббы алдындагы хуш исле сумала яндыру мәзбәхенең мөгезләренә сөртсен, ә калган канны Изге чатырга керү урыны янындагы корбан яндыру мәзбәхенең нигезенә түксен. [8-10] Шуннан соң Баш рухани, татулык корбаны үгезенең майларын аерып алган кебек, гөнаһ йолу корбаны булган үгез бозауның да бөтен маен – эчке әгъзаларын каплаган эч маен, ике бөерен, бөер өстендәге, шулай ук биле янындагы маен һәм бавыр астындагы өлешен аерып алсын. Аннары аларны корбан яндыру мәзбәхендә яндырсын. [11-12] Ә тиресен, башын, аяклары белән барлык итен, эчке әгъзаларын, шулай ук эчендәге шакшыларын, гомумән, үгез бозауны бөтен килеш тукталу урыныннан читкә алып чыгып, көл түгелә торган чиста бер урында утын өстендә яндырсын.

[13] Әгәр дә бөтен Исраил җәмәгатьчелеге, ниятләмичә, гөнаһ кылса – Раббының боерыгына каршы килүче берәр эш эшләсә, халык, үзенең гөнаһ кылганлыгын белмәсә дә, гаепле була. [14] Кылган гөнаһы билгеле булганнан соң, җәмәгатьчелек Изге чатыр алдына, гөнаһ йолу корбаны итеп, бер үгез бозау китерергә тиеш.
[15] Җәмәгатьчелекнең аксакаллары Раббы алдында кулларын үгез бозауның башына куйсыннар, һәм үгез бозау суелсын. [16] Баш рухани үгез бозау канының бер өлешен Изге чатыр эченә китерсен.
[17] Үзенең бармагын канга манчысын да Раббы каршында Изге чатыр эчендәге пәрдә алдында канны җиде тапкыр сипсен. [18] Берникадәр канны Изге чатыр эчендә булган Раббы алдындагы хуш исле сумала яндыру мәзбәхенең мөгезләренә сөртсен; ә калган канны Изге чатырга керү урыны янындагы корбан яндыру мәзбәхенең нигезенә түксен. [19] Ә маен аерып алып, аны мәзбәхтә яндырсын. [20] Баш рухани үзенең гөнаһ йолу корбаны булган үгез бозау белән ничек

эшләсә, бу үгез бозау белән дә шулай ук эшләсен. Шул рәвешле, Баш рухани бу эшне халык үз гөнаһыннан арынсын өчен башкарыр, һәм халыкның гөнаһы кичерелер.
21 Баш рухани үзенең гөнаһы өчен китергән үгез бозавын тукталу урыныннан читкә алып чыгып ничек яндырса, монысын да шулай яндырсын. Бу – җәмәгатьчелекнең гөнаһ йолу корбаны.

22 Әгәр берәр җитәкче, ниятләмичә, гөнаһ кылса – Раббының, үзенең Алласының боерыгына каршы килүче берәр эш эшләсә, ул гаепле була.
23 Кылган гөнаһы билгеле булганнан соң, әлеге җитәкче корбан итеп кимчелексез бер кәҗә тәкәсе китерергә тиеш.
24 Ул үзенең кулын кәҗә тәкәсенең башына куйсын, шуннан соң аны тулаем яндыру корбанын чалу урынында Раббы алдында чалсын. Бу – гөнаһ йолу корбаны.
25 Рухани үзенең бармагы белән гөнаһ йолу корбанының берникадәр канын алып, аны корбан яндыру мәзбәхенең мөгезләренә сөртсен, ә калган канны мәзбәхнең нигезенә түксен.
26 Аның бөтен маен, татулык корбанының маен яндырган кебек, мәзбәхтә яндырсын. Шул рәвешле, рухани моны җитәкче үз гөнаһыннан арынсын өчен башкарыр, һәм аның гөнаһы кичерелер.

27 Әгәр ил халкы арасыннан берәү, ниятләмичә, гөнаһ кылса – Раббының боерыкларына каршы килүче берәр эш эшләсә, ул гаепле була.
28 Эшләгән гөнаһы үзенә белдерелгәч, ул, кылган гөнаһы өчен корбан итеп, кимчелексез бер кәҗә китерергә тиеш.
29 Үзенең кулын гөнаһ йолу корбанының башына куеп, тулаем яндыру корбанын чалу урынында аны чалсын.
30 Рухани үзенең бармагы белән корбанның берникадәр канын алып, аны корбан яндыру мәзбәхенең мөгезләренә сөртсен, ә канның калган өлешен мәзбәхнең нигезенә түксен.
31 Корбанның бөтен маен, татулык корбанының маен аерып алган кебек, аерып алсын да, хуш исен Раббы алдында чыгарырлык итеп, ул майны мәзбәхтә яндырсын. Шул рәвешле, рухани моны әлеге кеше үз гөнаһыннан арынсын өчен башкарыр, һәм аның гөнаһы кичерелер.

32 Әгәр кеше гөнаһ йолу корбаны итеп бәрән китерергә тели икән, ул кимчелексез ана женестән булырга тиеш.
33 Шул кеше кулын корбанының башына куйсын һәм тулаем яндыру корбанын чалу урынында аны чалсын.
34 Ә рухани исә бармагы белән гөнаһ йолу корбанының берникадәр канын алсын да корбан яндыру мәзбәхенең мөгезләренә сөртсен, ә канның калган өлешен мәзбәхнең нигезенә түксен.
35 Аның бөтен маен, татулык корбаны итеп чалынган сарыкның маен аерып алган кебек, аерып алсын да мәзбәхтә Раббыга багышлап яндырылган башка корбаннар өстенә куеп яндырсын. Шул рәвешле, рухани моны әлеге кеше үз гөнаһыннан арынсын өчен башкарыр, һәм аның гөнаһы кичерелер.

# 5

[1] Кем дә булса берәү үзе күргән яки белгән нindидер эшкә
шаһит булса, әмма бу хакта хәбәр итмәсә, ул гөнаһлы була.
Ул җәзага тартылырга тиеш.
[2] Әгәр кем дә булса берәү нәҗес* булган берәр нәрсәгә, нәҗес
ерткыч җәнлекнең яисә нәҗес хайванның үләксәсенә, яки сөйрә-
лүче нәҗес хайван үләксәсенә кагылса, үзе шул турыда белмәсә
дә, ул кеше нәҗес һәм гаепле була.
[3] Әгәр берәү нинди дә булса кеше нәҗеслегенә кагылса, башта
үзе шул хакта белмичә, соңыннан гына белсә дә, ул гаепле була.
[4] Әгәр берәү, уйламыйча, игътибарсызлык нәтиҗәсендә ант итсә,
ул антның яхшылыккамы яки яманлыккамы икәнен үзе дә белми-
чә калып, соңыннан гына белсә дә, бу кеше гаепле була.
[5] Әгәр берәр кеше шушы эшләрнең берсендә гаепле булса, ул
үзенең гөнаһын танып сөйләргә тиеш; [6] ул, кылган гаебенә карап,
гөнаһ йолу корбаны итеп, Раббыга вак терлек – сарык яки кәҗә
китерергә тиеш, һәм рухани, ул кеше үзенең гөнаһыннан арынсын
өчен, корбан китерер.
[7] Әгәр дә инде ул кешенең сарык яки кәҗә китерерлек хәле бул-
маса, ул үзенең гаебе өчен Раббыга ике урман күгәрчене яки ике ба-
ла күгәрчен китерсен; аларның берсе гөнаһ йолу корбаны, икенчесе
тулаем яндыру корбаны булыр. [8] Ул кеше күгәрченнәрне руханига
китерсен; рухани башта ул кошларның гөнаһ йолу өчен булганының
башын муеныннан өзсен, ләкин аермасын, [9] һәм бу гөнаһ йолу кор-
банының берникадәр канын мәзбәхнең як-ягына сипсен, канның
калган өлешен мәзбәхнең нигезенә агызсын. Бу – гөнаһ йолу кор-
баны. [10] Ә икенче күгәрченне исә, тулаем яндыру корбаны итеп,
канун буенча китерсен. Рухани моны ул кеше үзе кылган гөнаһтан
арынсын өчен башкарыр, һәм аның гөнаһы кичерелер.
[11] Әгәр дә инде ул ике урман күгәрчене яки ике бала күгәрчен
китерерлек хәлдә булмаса, алар урынына, кылган гөнаһы өчен, гө-
наһ йолу корбаны итеп, бер епаның* уннан бер өлеше кадәр иң
яхшы бодай оны китерсен; әмма аның өстенә зәйтүн мае сибелергә
һәм өстенә хуш исле сумала куелырга тиеш түгел, чөнки бу – гөнаһ
йолу корбаны. [12] Ул аны руханига китерсен, ә рухани, аннан бер уч
он алып, бу өлеш барлык бүләкнең бер өлеше буларак, аны мәз-
бәхтә Раббыга багышлап яндыру бүләкләре өстендә яндырсын. Бу –
гөнаһ йолу корбаны. [13] Шул рәвешле, рухани моны ул кеше үзе кыл-
ган гөнаһтан арынсын өчен башкарыр, һәм аның гөнаһы кичере-
лер; калган он исә, икмәк бүләге кебек үк, руханига тапшырылыр».

---

* **5:2** *Нәҗес* – яһүд дине буенча болар нәҗес һәм кабул ителми дип исәп-ләнә.
* **5:11** *Епа* – 10-20 литр чамасы.

*Гаеп йолу корбаны*

14 Раббы Мусага болай диде:
15 – Әгәр дә берәү, ниятләмичә, тугры булмаса – Раббыныкы
булган изге берәр әйберне Аңа бирмәсә, ул үзенең гаебе өчен, гаеп
йолу корбаны итеп, Раббыга вак терлекләрдән кимчелексез сарык
тәкәсе китерергә тиеш. Бу сарык тәкәсенең бәясе рәсми бәя буен-
ча көмеш белән билгеләнсен. 16 Шул кеше изге әйбер өчен түләргә
һәм, бәясенең биштән бер өлеше кадәр өстәп, аны руханига би-
рергә тиеш. Рухани, ул кеше үзенең гаебеннән арынсын өчен, шул
сарык тәкәсен корбанга китерер, һәм аның гаебе кичерелер.
17 – Кем дә булса гөнаһ кылса – Раббының боерыгына каршы
килүче берәр эш эшләсә, моны үзе белмәсә дә, әлеге кеше гаепле
була. Ул җәзага тартылырга тиеш. 18 Гөнаһ кылган кеше руханига,
гаеп йолу корбаны итеп, вак терлекләрдән кимчелексез сарык тә-
кәсе китерергә тиеш. Бу сарык тәкәсенең бәясе рәсми бәя буенча
билгеләнсен. Шул рәвешле, рухани, ул кеше үзенең белмичә кыл-
ган гаебеннән арынсын өчен, корбан китерер, һәм аның гаебе ки-
черелер. 19 Бу – гаеп йолу корбаны, чөнки әлеге кеше Раббы кар-
шында гаепле булды.

# 6

1 Раббы Мусага болай диде:
2 – Әгәр берәү, Раббы алдында тугры булмыйча, түбәндәге
гөнаһлы эшләрне эшләсә: иптәшенең әманәтен кире кайтар-
маса яисә аның берәр әйберен урласа, яки хәйләләп алдаса, 3 яки
югалган әйберне табып та, «тапмадым» дип алдашса, яисә нинди
дә булса гөнаһлы эшләре турында ялган ант итсә, 4-5 ул кеше гө-
наһка керә һәм гаепле була; шунлыктан, нәрсә урлаган булса –
шуны, нәрсә ялганлап алган булса – шуны, нәрсә әманәт ителгән
булса – шуны, нинди югалган нәрсәне тапкан булса – шуны, нәр-
сәдә ялган ант иткән булса – шуны кире кайтарып бирергә тиеш.
Ул үзенең гаебе өчен корбан китергән вакытта, әйбер бәясенең
биштән бер өлеше кадәр өстәп, әйберне хуҗасына кайтарып би-
рергә тиеш. 6 Үзенең гаебе өчен, Раббыга гаеп йолу корбаны итеп,
вак терлекләрдән руханига кимчелексез сарык тәкәсе китерергә
тиеш. Бу сарык тәкәсенең бәясе рәсми бәя буенча билгеләнсен.
7 Шул рәвешле, рухани, ул кеше үз гаебеннән арынсын өчен, Раббы
алдына корбан китерер, һәм аның гаебе кичерелер.

*Тулаем яндыру корбаны турындагы канун*

8 Раббы Мусага болай диде:
9 – Һарун һәм аның угылларына әмер ит: «Тулаем яндыру кор-
баны кануны шундый: тулаем яндыру корбаны иртәнгә кадәр төн
буена мәзбәхтә калырга һәм аның уты янып торырга тиеш. 10 Рухани

үзенең җитен киемнәре белән бергә эчтән җитен ыштанын киеп,
мәзбәхтә тулаем яндыру корбанының көлен алып торсын һәм аны
мәзбәхнең кырыена өйсен. 11 Шуннан соң ул теге киемнәрен са-
лып, башка киемнәр кисен һәм әлеге көлне тукталу урыныннан
чиста бер урынга алып чыксын. 12 Ә мәзбәхтә ут янып торырга,
сүнмәскә тиеш. Рухани һәр көн иртә белән аңа утын өстәп торсын
һәм тулаем яндыру корбанын аның өстенә тезеп куеп, әлеге кор-
банның өстендә татулык корбанының маен яндырсын. 13 Мәзбәх-
тәге ут һәрвакыт янып торырга, сүнмәскә тиеш».

*Икмәк бүләге турындагы канун*

14 «Ә менә икмәк бүләге кануны түбәндәгечә: Һарунның угылла-
ры аны Раббы каршына, мәзбәх алдына китерергә тиешләр. 15 Ру-
хани икмәк бүләгеннән учын тутырып иң яхшы бодай онын һәм
зәйтүн маен, бөтен хуш исле сумаланы алып, бу өлеш барлык бү-
ләкнең бер өлеше буларак, аны мәзбәхтә яндырсын. Ул Раббы ал-
дында хуш ис чыгарыр. 16 Ә калганын Һарун һәм аның угыллары
ашасын; бу икмәк чүпрәсез булырга тиеш. Аны изге урында – Изге
чатырның ишегалдында ашасыннар. 17 Бу икмәкне чүпрә белән
пешермәскә. Мин аны аларга Үземә багышлап яндыру бүләклә-
ремнән бирәм. Бу – гөнаһ йолу корбаны һәм, гаеп йолу корбаны
кебек, тулысынча изге. 18 Һарунның барлык ир-ат нәсел варислары
аны ашый ала. Бу – буыннан-буынга Раббыга багышлап яндыру
бүләкләреннән аларның мәңгелек өлеше. Кем дә булса берәү, уй-
ламыйча, аңа кагылса, ул кеше үзен Раббыга тапшырсын».
19 Раббы Мусага болай диде:
20 – Һарунны руханилыкка багышлау өчен майлаячак көнне Һа-
рун һәм аның угылларының Раббыга китерәчәк бүләге менә шу-
шы: даими икмәк бүләге өчен бер епаның уннан бер өлеше кадәр
иң яхшы бодай оны – яртысы иртә беләнгә, яртысы – кичкә. 21 Бу
икмәк бүләге, зәйтүн мае белән кушылып, табада пешерелергә ти-
еш; бу бүләк, кисәкләргә бүленеп, Раббы алдына китерелсен. Ул
Раббы алдында хуш ис чыгарыр. 22 Бу эшләрне Һарун урынына ка-
лачак угылларыннан берсе – Баш рухани башкарсын; бу бүләк –
мәңгегә Раббыныкы; аның бөтенесе яндырылырга тиеш. 23 Шулай
итеп, рухани китергән икмәк бүләгенең бөтен төре дә ашалырга
түгел, ә яндырылырга тиеш.

*Гөнаһ йолу корбаны турындагы канун*

24 Раббы Мусага болай диде:
25 – Һарунга һәм аның угылларына игълан ит: «Гөнаһ йолу кор-
баны турындагы канунда болай диелә: гөнаһ йолу корбаны Раббы
алдында тулаем яндыру корбаны чалына торган урында чалынсын;
бу – тулысынча изге корбан. 26 Гөнаһ йолу вазифасын башкаручы

рухани аны ашасын; ул изге урында, Изге чатырның ишегалдында
ашалсын. [27] Аның итенә кагылган бар нәрсә, Раббыга тапшыры-
лып, изгеләнсен. Әгәр аның каны кием-салымга чәчрәсә, кан чәч-
рәгән киемне изге урында юарга кирәк. [28] Ул ит пешерелгән бал-
чык савыт ватылырга, әгәр ит бакыр савытта пешерелсә, ул савыт
чистартылырга һәм су белән юылырга тиеш. [29] Рухани гаиләсеннән
булган һәр ир кеше ул итне ашый ала; бу – тулысынча изге кор-
бан. [30] Әгәр гөнаһ йолу корбанының каны, гөнаһ йолу өчен, Изге
чатырдагы Изге бүлмәгә* кертелсә, ул хайван ашалырга тиеш түгел; андый корбан утта яндырылырга тиеш».

*Гаеп йолу корбаны турындагы канун*

7 [1] «Гаеп йолу корбаны турындагы канун менә мондый: бу –
тулысынча изге корбан. [2] Корбан китерүче гаеп йолу корба-
нын тулаем яндыру корбаны чала торган урында чалсын, ә
рухани аның канын мәзбәхнең һәр ягына чәчрәтсен. [3-4] Аның бө-
тен маен, симез койрыгын, эчке әгъзаларын каплаган маен, ике
бөерен, шулай ук биле янындагы маен һәм бавыр астындагы өле-
шен аерып алып китерсен. [5] Ә рухани аларны, Раббыга багышлап
яндыру бүләге итеп, мәзбәхтә яндырсын. Бу – гаеп йолу корбаны.
[6] Рухани гаиләсеннән булган һәр ир кеше аны ашый ала; әмма ул
изге урында ашалырга тиеш, чөнки бу – тулысынча изге корбан.
[7] Гөнаһ йолу корбаны өчен дә, гаеп йолу корбаны өчен дә канун
бер төрле; бу корбанның ите – әлеге гөнаһ йолу вазифасын баш-
каручы руханиныкы. [8] Тулаем яндыру корбанын башкаручы рухани
бу корбанның тиресенә ия булсын. [9] Мичтә, чүлмәктә яки табада
пешерелгән һәр икмәк бүләге – аны башкаручы руханиныкы.
[10] Май кушылган яки кушылмаган һәртөрле пешерелмәгән икмәк
бүләге Һарун угылларыныкы һәм ул алар арасында тигез итеп бү-
ленсен».

*Татулык корбаны турындагы канун*

[11] «Раббыга тәкъдим ителә торган татулык корбанының кануны
түбәндәгечә: [12] кем дә булса берәү шөкер итеп татулык корбанын
китерә икән, аның белән бергә зәйтүн мае кушылган төче икмәк-
ләр, зәйтүн мае белән майланган юка төче көлчәләр яки зәйтүн
мае кушылган иң яхшы бодай оныннан пешерелгән икмәкләр ки-
терсен. [13] Болардан тыш ул шөкер итеп, татулык корбаны белән
бергә, чүпрәле икмәк тә китерсен. [14] Һәртөрле икмәк бүләгенең

---

* 6:30 *Изге бүлмә* – Изге чатыр эчендәге ике бүлмәнең берсе. Бу бүлмә Иң изге бүлмәдән зур пәрдә белән аерып алынган һәм анда хуш исле сумала яндыру мәзбәхе, шәмдәл һәм изге икмәк кую өстәле куелган булган (карагыз: «Чыгыш» китабы 26:33, 35).

бер өлешен Раббыга багышлап китерсен; ул татулык корбанының
канын мәзбәхнең һәр ягына чәчрәтүче руханиныкы булыр. 15 Кор-
бан китерүче шөкер итү корбаны итен тәкъдим иткән көнне үк
ашарга тиеш, аны иртәнгә калдырырга ярамый.

16 Әгәр кем дә булса корбанын нәзер әйтеп яки ихтыяри рәвеш-
тә китерә икән, аның итен, әгәр тәкъдим ителгән көннән калса,
икенче көнне дә ашарга ярый. 17 Әгәр әлеге корбан ите өченче көн-
гә дә калса, ул утта яндырылырга тиеш. 18 Татулык корбанының
ите өченче көнне дә ашала икән, бу корбан Раббы тарафыннан
кабул ителмәс һәм корбан китерүчегә аның савабы хисапланмас;
бу ит нәҗесле, һәм өченче көнне аны ашаучы җәзага тартылырга
тиеш. 19 Бу иткә нинди дә булса нәҗес нәрсә тигән булса, аны
ашарга ярамый, ул ит утта яндырылырга тиеш; ә чиста итне һәр
чиста кешегә ашарга рөхсәт. 20 Әгәр дә берәр нәҗес кеше Раббы-
ның татулык корбаны итен ашый икән, андый кеше үз халкыннан
читләштерелергә тиеш. 21 Әгәр берәү нинди дә булса нәҗес нәрсә-
гә: кеше нәҗеслегенә, нәҗес хайван яисә нәҗес хәрам әйбергә ка-
гылса һәм Раббының татулык корбаны итен ашаса, андый кеше үз
халкыннан читләштерелергә тиеш».

22 Янә Раббы Мусага болай диде:

23 – Исраиллеләргә игълан ит: «Сыер маен да, сарык маен да,
кәҗә маен да ашамагыз. 24 Үзе үлгән яки ерткыч җанвар ботарла-
ган җәнлек маен һәртөрле эшкә файдаланырга мөмкин, әмма аны
ашарга ярамый. 25 Әгәр кем дә булса берәү Раббыга багышлап ян-
дыру бүләге китерергә яраклы хайванның маен ашый икән, андый
кеше үз халкыннан читләштерелергә тиеш. 26 Кайда гына яшәсәгез
дә, кош канын да, хайван канын да ашамагыз. 27 Ә инде кем дә
булса берәү нинди дә булса кан ашый икән, андый кеше үз хал-
кыннан читләштерелергә тиеш».

28 Раббы Мусага янә болай диде:

29 – Исраиллеләргә игълан ит: «Татулык корбанын Раббыга ки-
терүче кеше шул корбанның бер өлешен Раббыга китерергә тиеш.
30 Ул үзенең Раббыга багышлап яндыру бүләген үз куллары белән
китерсен; корбанының маен күкрәге белән бергә китереп, күкрәген,
махсус бүләк итеп, Раббы алдында селкетсен. 31 Рухани корбанның
маен мәзбәхтә яндырсын, ә күкрәге исә Һарунга һәм аның угылла-
рына булыр. 32 Татулык корбанының арткы уң ботын руханига бүләк
итеп бирегез. 33 Һарун угылларыннан берәрсе татулык корбанының
канын һәм маен тәкъдим итсә, корбанның арткы уң боты да аңа би-
релсен. 34 Мин исраиллеләрнең татулык корбаннарыннан селкетел-
гән күкрәген һәм тәкъдим ителгән арткы уң ботын алып, аларны
мәңгелеккә рухани Һарунга һәм аның угылларына бирәм».

35 Руханилык вазифасын үтәү өчен Һарун һәм аның угыллары
Раббыга багышланган көннән соң, Раббыга багышлап яндыру

бүләкләреннән аларга билгеләнгән өлеш менә шул. [36] Алар рухани
итеп майланган көнне ул өлешнең исраиллеләр тарафыннан руха-
ниларга бирелергә тиешлеген Раббы әмер итте. Бу аларның киләчәк
буыннарына мәңгелек кагыйдә.

[37] Тулаем яндыру корбаны, икмәк бүләге, гөнаһ йолу корбаны,
гаеп йолу корбаны, руханилыкка багышлау йоласы корбаны һәм
татулык корбаны хакындагы канун менә шул. [38] Синай чүлендәге
Синай тавында Раббы исраиллеләрнең Раббыга корбаннар ките-
рергә тиешлеге хакында Мусага менә шуларны әмер итте.

*Һарун һәм аның угылларының рухани итеп майлануы*

**8** [1] Раббы Мусага болай диде:
[2-3] – Һарунны һәм аның угылларын, киемнәрен, изгеләндерү
маен, гөнаһ йолу корбаны өчен үгез бозау, ике сарык тәкәсе,
бер кәрзин төче икмәк ал да барча халыкны Изге чатырга керү
урыны алдына җый.

[4] Муса, Раббы аңа ничек әмер иткән булса, шулай эшләде: ха-
лык Изге чатырга керү урыны алдына җыелды. [5] Шуннан соң Муса
халыкка:

– Раббы миңа шулай эшләргә әмер итте, – диде.

[6-7] Муса Һарунны, аның угылларын алып килде дә аларны су бе-
лән юындырды; Һарунга күлмәк кидерде, биленә пута бууды, аның
өстенә япанча кидерде; руханилык алъяпкычы яптырып, өстеннән
яхшы тукылган билбау белән бәйләде; шул рәвешле, руханилык
алъяпкычын аның өстенә беркетте. [8] Аның өстенә руханилык күк-
рәкчәсен каплап, күкрәкчә эченә изге җирәбәләр* куйды. [9] Башы-
на тюрбан кидерде һәм, Раббы әмер иткәнчә, тюрбанның алгы
ягына алтынланган изгелек билгесен куйды.

[10] Шуннан соң Муса, изгеләндерү маен алып, чатырны һәм аның
эчендәге бар нәрсәне майлады; шул рәвешле, ул аларны изгелән-
дерде. [11] Майның бер өлешен алып, җиде мәртәбә мәзбәхкә, аның
бөтен әсбапларына, юынгыч һәм аның аскуймасына сипте; шулай
итеп, аларны изгеләндерде. [12] Муса, Һарунны изгеләндерү өчен, бер-
никадәр изгеләндерү маен аның башына агызды һәм аны майлады.
[13] Шуннан соң Муса Һарунның угылларын алып килде һәм, Раббы
кушканча, аларга күлмәк кидерде, пута белән билләрен бууды,
башларына баш киемнәре кидерде.

[14] Аннары ул гөнаһ йолу корбаны булган үгез бозау алып кил-
де; Һарун һәм аның угыллары кулларын үгез бозауның башына

---

* **8:8** *Изге җирәбәләр* – бу сүзләр яһүдчә «урим һәм туммим» дигән тәгъ-
бирне аңлата. Аллаһының ихтыярын белү өчен, рухани шулардан файда-
ланган.

куйдылар. [15] Шуннан соң Муса аны чалды һәм берникадәр канын ал-
ды, бармагы белән мәзбәхнең мөгезләренә һәрьяклап сөртеп, мәз-
бәхне чистартты, ә канның калган өлешен мәзбәх нигезенә түкте.
Шул рәвешле, нәҗеслектән чистартып, ул аны изгеләндерде. [16] Муса
үгез бозауның бөтен эчке әгъзаларын каплаган маен, бавыр астында-
гы өлешен, мае белән бергә ике бөерен алып, аларны мәзбәхтә ян-
дырды. [17] Ул, Раббы кушканча, үгез бозауны, аның тиресен, итен һәм
эчендәге шакшыларын тукталу урынының тышында яндырды.

[18] Аннан соң Муса тулаем яндыру корбаны булган сарык тәкә-
сен алып килде; Һарун һәм аның угыллары кулларын тәкәнең ба-
шына куйдылар. [19] Муса аны да чалды һәм канын мәзбәхнең һәр
ягына чәчрәтте. [20] Ул тәкәне кисәкләргә бүлде һәм башын, кисәк-
ләрен, маен утта яндырды. [21] Ул аның эчендәге әгъзаларын һәм
аякларын су белән юды да бөтен тәкәне, тулаем яндыру корбаны
итеп, мәзбәхтә яндырды. Менә бу, Раббы Мусага әмер иткәнчә,
Раббыга багышлап яндыру бүләге; ул хуш ис чыгарды.

[22] Муса янә икенче сарык тәкәсен алып килде, монысы рухани-
лыкка багышлау йоласы корбаны иде, Һарун һәм аның угыллары
кулларын тәкәнең башына куйдылар. [23] Муса аны да суйды һәм
аның берникадәр канын алып, Һарунның уң колак яфрагына, уң
кулының һәм уң аягының баш бармакларына сөртте. [24] Муса Һарун-
ның угылларын алып килде һәм канны аларның уң колак яфрак-
ларына, шулай ук уң кулларының һәм уң аякларының баш бар-
макларына тидерде, ә канның калганын мәзбәхнең һәр ягына чәч-
рәтте. [25-26] Шуннан соң ул тәкәнең маен, симез койрыгын, бөтен
эчке әгъзаларын каплаган маен, аның бавыр астындагы өлешен,
майлары белән бергә ике бөерен һәм арткы уң ботын алды; һәм
Раббы алдында булган кәрзиндәге төче икмәкләрдән бер күмәч, бер
майлы икмәк һәм бер юка көлчә алды да аларны корбанның май-
лары һәм арткы уң боты өстенә куйды. [27] Боларның һәммәсен Һа-
рун һәм аның угылларының кулларына бирде, һәм алар, шуларны
селкетеп, Раббы алдына махсус бүләк итеп китерделәр. [28] Аннары
Муса барысын да аларның кулларыннан алып, мәзбәхтә тулаем
яндыру корбаны өстендә руханилыкка багышлау йоласы корбаны
итеп яндырды. Бу – Раббыга багышлап яндыру бүләге; ул хуш ис
чыгарды. [29] Муса корбанның күкрәген алып, махсус бүләк итеп аны
Раббы алдында селкетте; бу – руханилыкка багышлау йоласы кор-
баны булган сарык тәкәсеннән Мусага тигән өлеш. Муса моны
Раббы әмер иткәнчә эшләде.

[30] Аннары Муса берникадәр изгеләндерү маен һәм мәзбәхтәге
канның бер өлешен алып, Һарунга һәм аның угылларына, шулай
ук аларның киемнәренә сипте; шул рәвешле, ул Һарунны һәм
аның киемнәрен, аның белән бергә угылларын һәм угылларының
киемнәрен изгеләндерде.

31 Муса Һарунга һәм аның угылларына болай диде:
– Изге чатырга керү урыны алдында ит пешерегез һәм аны шунда руханилыкка багышлау йоласы корбаны кәрзинендәге икмәк белән ашагыз; чөнки миңа: «Аны Һарун һәм аның угыллары ашарга тиеш», – дип әмер ителде. 32 Ә калган ит белән икмәкне
яндырыгыз. 33 Үзегезне руханилыкка багышлау йоласы тәмамланганчы җиде көн буена Изге чатырга керү урыныннан читкә китмәгез, чөнки бу җиде көнгә сузылачак. 34 Сезне гөнаһтан арындыру
өчен, бүген сезгә эшләнгән кебек итеп эшләргә Раббы әмер бирде.
35 Җиде көн буена көндез һәм төнлә Изге чатырга керү урыны төбендә торыгыз һәм, үлмәс өчен, Раббы таләп иткәнчә эшләгез; чөнки миңа шулай әмер ителде.

36 Һарун һәм аның угыллары Раббының Муса аша җиткерелгән әмерләрен тулысынча үтәделәр.

*Руханиларның эшли башлавы*

# 9

1-2 Сигезенче көнне Муса Һарунны, аның угылларын һәм Исраилнең аксакалларын чакырып алды да Һарунга болай диде:
– Үзеңә гөнаһ йолу корбаны итеп кимчелексез бер үгез бозау, ә тулаем яндыру корбаны итеп кимчелексез бер сарык тәкәсе ал да
Раббы алдына тәкъдим ит. 3-4 Шуннан исраиллеләргә игълан ит: «Раббы алдында корбан итү өчен гөнаһ йолу корбаны итеп бер кәҗә тәкәсе, тулаем яндыру корбаны итеп берәр яшьлек кимчелексез бер бозау белән бер бәрән, татулык корбаны итеп бер үгез белән бер сарык тәкәсе һәм зәйтүн мае кушылган икмәк бүләге алыгыз, чөнки бүген сезнең алда Раббы пәйда булачак».

5 Муса әмер иткән нәрсәләрне Изге чатыр алдына китерделәр, барча халык та шунда килде һәм Раббы алдында басып торды.
6 Муса болай диде:
– Раббының әмер иткәне менә шушы инде, шуңа күрә сезнең алда Раббының шөһрәте пәйда була ала.

7 Муса Һарунга әйтте:
– Раббы әмер иткәнчә, мәзбәх янына бар да, үзең һәм халык гөнаһтан арынсын өчен, гөнаһ йолу корбаныңны һәм тулаем яндыру корбаныңны тәкъдим ит, шулай ук, халык гөнаһтан арынсын өчен, халыкның корбанын тәкъдим ит.

8 Шуннан соң Һарун, мәзбәх янына килеп, үзе өчен гөнаһ йолу
корбаны булган үгез бозауны чалды. 9 Аның угыллары аңа кан алып
килделәр, һәм ул бармагын канга манчыды да мәзбәхнең мөгезләренә сөртте, ә калган канны мәзбәхнең нигезенә түкте. 10 Ә гө-
наһ йолу корбанының маен, бөерләрен, бавыр астындагы өлешен,
Раббы Мусага әмер иткәнчә, мәзбәхтә яндырды. 11 Ите белән тиресен исә тукталу урынының тышында яндырды.

[12] Шуннан соң Һарун тулаем яндыру корбанын чалды; угыллары
аңа кан алып килделәр, һәм ул шушы канны мәзбәхнең һәр ягына
чәчрәтте. [13] Аңа, тураклап, тулаем яндыру корбанын һәм корбан-
ның башын китерделәр, Һарун аларны мәзбәхтә яндырды; [14] ә эчке
әгъзаларын һәм аякларын, юып, мәзбәхтә – әлеге тулаем яндыру
корбаны өстендә яндырды.

[15] Шуннан Һарун халык тарафыннан бирелгән корбаннарны ки-
терде һәм халыкның гөнаһы өчен биргән кәҗә тәкәсен алып чал-
ды да, аны, элеккесе кебек, гөнаһ йолу корбаны итеп тәкъдим ит-
те. [16] Шулай ук тулаем яндыру корбаннарын да китерде – аларны
канун буенча тәкъдим итте. [17] Шуннан соң Һарун икмәк бүләге ки-
терде, аннан бер уч тутырып алды да, иртәнге тулаем яндыру кор-
банына өстәп, мәзбәхтә яндырды. [18] Аннары халык тарафыннан би-
релгән татулык корбаннары булган үгез белән сарык тәкәсен чалды;
Һарунның угыллары аңа кан китерделәр, һәм ул аны мәзбәхнең
һәр ягына чәчрәтте. [19-20] Алар үгезнең һәм сарык тәкәсенең майла-
рын – симез койрыгын, эч маен, бөерләрен һәм бавыр астындагы
өлешен алып, күкрәкләре өстенә куйдылар. Һарун шушы майларны
мәзбәхтә яндырды. [21] Шуннан Һарун үгезнең һәм сарык тәкәсенең
күкрәкләрен һәм арткы уң ботларын, Муса кушканча, махсус бү-
ләк итеп, Раббы алдында селкетте.

[22] Аннары Һарун, кулларын күтәреп, халыкка фатиха бирде. Гө-
наһ йолу корбанын, тулаем яндыру корбанын һәм татулык корба-
нын тәкъдим иткәннән соң, ул түбәнгә төште. [23] Шуннан соң Му-
са белән Һарун Изге чатырның эченә керделәр. Аннан чыккач, ха-
лыкка фатиха бирделәр. Менә шулвакыт барча халык алдында
Раббының шөһрәте пәйда булды. [24] Раббы алдыннан ут чыкты һәм
мәзбәх өстендәге тулаем яндыру корбанын һәм майларны яндыр-
ды; моны күргән барча халык шатлыктан кычкырып җибәрде дә
йөзләре белән җиргә ауды.

*Надаб белән Абиһуның үлеме*

**10**
[1] Һарунның угыллары – Надаб белән Абиһу – үзләренең
сумала төтәсләү савытларын алып, аларга ут төрттеләр
дә өстенә хуш исле сумала салдылар һәм Раббы алды-
на рөхсәт ителмәгән ут китерделәр, ә Раббы моны эшләргә куш-
маган иде. [2] Шулвакыт Раббы алдыннан ут кабынып китте, аларны
яндырды; һәм алар Раббы алдында үлделәр. [3] Шуннан Муса Һа-
рунга әйтте:

– «Руханилар Минем изгелегемә хөрмәт күрсәтергә,
Бөтен халык Мине данлыклы итәргә тиеш», –

дигән иде Раббы. Һарун эндәшмәде.

[4] Шуннан соң Муса, Һарунның абыйсы Уззиелнең угыллары Ми-
шаил белән Элсафанны чакырып алып, аларга болай диде:

— Бирегә килегез, туганнарыгызны Изге бүлмәдән — тукталу урыныннан — читкә чыгарыгыз.

[5] Алар килделәр һәм, Муса әйткәнчә, үлгән кешеләрнең киемнәреннән тотып, аларны тукталу урыныннан читкә чыгардылар.

[6] Муса Һарунга һәм аның угыллары Элгазар белән Итамарга болай диде:

— Үлмәс өчен һәм барча халыкка карата Раббының ачуы кабармасын өчен, сез чәчегезне тузгытмагыз һәм киемнәрегезне ерткаламагыз; туганнарыгыз һәм барча Исраил халкы, Раббы тарафыннан утта яндырылганнарны кызганып, кайгы кичерсеннәр. [7] Ә сез, үлмәс өчен, Изге чатырга керү урыныннан читкә китмәгез, чөнки сез, Раббының изгеләндерү мае белән майланып, Аңа багышландыгыз.

Алар нәкъ Муса кушканча эшләделәр.

*Руханилар эше турындагы кагыйдә*

[8] Раббы Һарунга болай диде:

[9] — Изге чатырга кергәндә, син һәм синең угылларың үлмәсен өчен, шәраб һәм каты эчемлекләр эчмәгез. Бу сезнең киләчәк буыннарыгызга мәңгелек кагыйдә. [10-11] Сез изгене изге булмаганнан, чистаны нәҗестән аера белергә һәм исраиллеләрне Раббының Муса аркылы җиткерелгән барлык кагыйдәләренә өйрәтергә тиеш.

[12] Муса Һарунга һәм аның исән калган угыллары Элгазар белән Итамарга болай диде:

— Раббыга багышлап яндыру бүләкләреннән булган икмәк бүләгенең калганын алып, төче икмәк пешерегез дә аны мәзбәх янында ашагыз, чөнки бу тулысынча изге. [13] Аны изге урында ашагыз, чөнки бу — Раббыга багышлап яндыру бүләкләреннән сезнең һәм сезнең угылларыгызның өлеше. Раббы бу хакта миңа шулай дип әмер итте. [14] Ә сез, угылларыгыз һәм кызларыгыз селкетелгән күкрәкне, шулай ук тәкъдим ителгән арткы уң ботны чиста урында ашагыз; чөнки бу — исраиллеләр биргән татулык корбаннарыннан сезгә һәм сезнең балаларыгызга тигән өлеш. [15] Шушы яндыру бүләкләренең майлары һәм махсус бүләк итеп тәкъдим ителгән арткы боты һәм селкетә торган күкрәге Раббы алдына китерелергә тиеш. Ул бот һәм күкрәк, Раббы әмер иткәнчә, сезнең һәм балаларыгызның мәңгелек өлеше.

[16] Муса гөнаһ йолу корбаны итеп китерелгән кәҗә тәкәсен эзләде, ләкин ул инде яндырылган иде. Муса, Һарунның исән калган угыллары Элгазар белән Итамарны ачуланып, алардан сорады:

[17] — Ни өчен сез гөнаһ йолу корбанын изге урында ашамадыгыз? Ул бит тулысынча изге, ул сезгә Раббы алдында халыкның гөнаһын йолу — халык гөнаһыннан арыну өчен бирелгән. [18] Менә аның каны Изге бүлмә эченә кертелмәде, миңа әмер ителгәнчә, сез аны изге урында ашарга тиеш идегез.

[19] Һарун Мусага болай диде:
– Менә бүген алар гөнаһ йолу корбаннарын һәм тулаем яндыру корбаннарын Раббы алдына китерделәр, ләкин бу хәл минем белән дә шулай булды; әгәр мин бүген гөнаһ йолу корбанын ашасам, Раббы моны мәгъкуль күрерме?
[20] Һарунның җавабын ишеткәч, Муса аның фикерен хуплады.

*Чиста һәм нәҗес хайваннар*

**11** [1] Раббы Мусага һәм Һарунга болай диде:
[2] – Исраиллеләргә игълан итегез: «Җир өстендә булган барлык хайваннардан сезгә ашарга яраклылары* түбәндәгеләр: [3] ярык тояклы күшәүче теләсә кайсы хайван. [4] Ярык тояклы гына яки күшәүче генә хайваннар ашалмаска тиеш. Дөя күшәсә дә, ярык тояклы түгел, ул сезнең өчен нәҗес була. [5] Шулай ук кушаяк, күшәсә дә, ярык тояклы түгел, сезнең өчен ул нәҗес була.
[6] Куян да, күшәсә дә, ярык тояклы түгел, сезнең өчен ул нәҗес була. [7] Дуңгыз, ярык тояклы булса да, күшәми; сезнең өчен ул нәҗес була. [8] Аларның итен ашамагыз һәм үләксәләренә кагылмагыз, алар сезнең өчен нәҗес була.
[9] Суда яшәүче хайваннардан түбәндәгеләрне ашарга ярый: диңгезләрдә, елгаларда яшәүче канатлы һәм тәңкәле булганнарның һәммәсен. [10] Диңгезләрдә, елгаларда яшәүчеләрнең канаты һәм тәңкәсе булмаганнары – мыжлап йөзүчеме, суда яшәүче бүтән хайванмы, барысы да сезнең өчен хәрам. [11] Болар сезнең өчен хәрам, аларның итен ашамагыз, үләксәләренә кагылмагыз. [12] Суда яшәүче канатсыз һәм тәңкәсез хайваннарның барысы да сезнең өчен хәрам.
[13-19] Кошлардан түбәндәгеләре сезнең өчен хәрам: бөркет, гриф, диңгез бөркете, тилгән, барлык лачыннар, һәртөрле козгыннар, тәвә кошы, ябалак, акчарлак, карчыга һәм аның токымыннан булганнары, байгыш, балык аулаучы, ибис, аккош, чүл ябалагы, сип, ләкләк, барлык челәннәр, һөдһөд һәм ярканат. Аларны ашарга ярамый.
[20] Дүрт аякта йөрүче канатлы бөҗәкләрнең һәммәсе сезнең өчен хәрам. [21] Әмма җир өстендә сикереп йөрү өчен ялганган аяклары булган канатлы бөҗәкләрне ашарга мөмкин. [22] Саранча һәм аның токымыннан булганнарны, барлык чикерткәләрне һәм шөрчекләрне дә ашарга ярый. [23] Дүрт аягы булган калган барлык канатлы бөҗәкләр сезнең өчен хәрам.

---

* **11:2** *Ашарга яраклылары* – үсемлек белән тукланучы хайваннар – ашарга яраклы, ә ит белән тукланучы хайваннар ашарга яраксыз дип исәпләнә. («Яратылыш» китабы 1:30 һәм 9:3 буенча Раббы хайваннарга азык итеп үсемлек кенә биргән.)

24 Алардан сез нәҗес булырсыз. Аларның үләксәләренә кагылган
һәркем кичкә кадәр нәҗес булыр. 25 Аларның үләксәсен тотып ал-
ган һәркем үзенең киемнәрен юарга тиеш, һәм ул кичкә кадәр нә-
җес булыр. 26 Ярык тояклы булмаган яки күшәмәүче теләсә кайсы
хайван сезнең өчен нәҗес; аларның үләксәсенә кагылган һәркем
нәҗес булыр. 27 Дүрт аяклы барлык җәнлекләр арасыннан аяк таба-
нында йөрүчеләре сезнең өчен нәҗес; аларның үләксәләренә ка-
гылган һәркем кичкә кадәр нәҗес булыр. 28 Аларның үләксәләрен
тотып алган һәркем үзенең киемнәрен юарга тиеш, һәм ул кичкә
кадәр нәҗес булыр; алар сезнең өчен нәҗес.

29-30 Җир өстендә сөйрәлүче хайваннар арасыннан сезнең өчен
чиста булмаганнары менә болар: сукыр тычкан, тычкан, кәлтә һәм
аның токымыннан булганнары. 31 Барлык сөйрәлүчеләр арасыннан
сезнең өчен чиста булмаганнары менә шулар. Аларның үләксәлә-
ренә кагылган теләсә кем кичкә кадәр нәҗес булыр. 32 Әгәр бу хай-
ваннардан берәрсе үлеп, нинди дә булса эштә кулланыла торган
берәр әйбергә: агач әйбергә, кием-салымга, тирегә яки капчыкка
төшсә, алар барысы да нәҗес булыр, һәм аларны юарга кирәк,
алар кичкә кадәр нәҗес булыр, шуннан соң чиста булыр. 33 Шу-
лардан берәрсенең үлек гәүдәсе нинди дә булса балчык савыт эче-
нә төшсә, савыт эчендәге әйбер нәҗес булыр, ул савыт ватылырга
тиеш. 34 Әгәр ул савыттан ашый торган берәр ризык өстенә су са-
лынса, ул ризык нәҗес булыр һәм андый савыт эчендәге һәртөрле
эчемлек тә нәҗес булыр. 35 Аларның үләксәләре төшкән бар нәрсә
нәҗес булыр; мич һәм учак кисәкләргә ватылырга тиеш. Алар сез-
нең өчен нәҗес. Аларны нәҗес исәпләгез. 36 Чишмә яки су саклау
урыны гына чиста булыр. Кем дә булса ул хайванның үләксәсенә
кагылса, ул кеше нәҗес булыр. 37 Үләксәнең нинди дә булса өлеше
чәчүлек орлыгы өстенә төшсә, ул орлык чиста килеш калыр. 38 Ә
инде үләксәдән нәрсә дә булса су сибелгән орлык өстенә төшсә,
ул орлык сезнең өчен нәҗес булыр.

39 Нинди дә булса ашарга яраклы хайван үлсә, аның үләксәсенә
кагылган кеше кичкә кадәр нәҗес булыр. 40 Әлеге хайванның итен
ашаган кеше үзенең киемнәрен юарга тиеш һәм ул кичкә кадәр
нәҗес булыр; үлгән хайванның үләксәсен тоткан кеше дә үзенең
киемнәрен юарга тиеш, һәм ул кичкә кадәр нәҗес булыр.

41 Җир өстендә сөйрәлүче һәр хайван сезнең өчен хәрам, аны
ашарга ярамый. 42 Җир өстендә сөйрәлүчеләрнең – корсаклары
белән шуышучылар, дүрт аякта йөрүчеләр яки күбаяклыларның –
берсен дә ашамагыз, чөнки алар хәрам. 43 Бернинди дә сөйрәлүче
белән җаныгызны нәҗесләмәгез һәм алар белән үзегезне пычрат-
магыз. Алар сезне пычратмасын. 44 Мин – Раббы Аллагыз; үзегезне
изгеләндерегез һәм изге булыгыз, чөнки Мин – изге; җир өстендә
сөйрәлүче берни белән дә үзегезне пычратмагыз. 45 Мин, сезнең

Аллагыз булу өчен, сезне Мисыр җиреннән алып чыккан Раббымын, шулай булгач, изге булыгыз, чөнки Мин – изге.

[46] Хайваннар, кошлар, суда яшәүче һәм җир өстендә сөйрәлүче барлык хайваннар хакындагы канун менә шушы. [47] Сез нәҗесне чистадан, ашарга яраклы хайванны ашарга ярамаганнан аерырга тиеш».

*Бала тудыру турындагы канун*

**12** [1] Раббы Мусага болай диде:
[2] – Исраиллеләргә игълан ит: «Әгәр бер хатын балага узып, ир бала тудырса, ул хатын, күрем күрү вакытындагы кебек, җиде көн нәҗес булыр. [3] Ир баланы сигезенче көндә сөннәткә утыртырга кирәк; [4] ә хатын-кыз кан китүдән чистарынганчы утыз өч көн тик утырырга, чистарыну* көннәре тулганга кадәр, һичнинди изге нәрсәгә кагылмаска, Изге чатырга кермәскә тиеш.

[5] Әгәр хатын-кыз кыз бала тудырса, күрем күрү вакытындагы кебек, ике атна нәҗес булыр һәм, кан китүдән чистарынганга кадәр, алтмыш алты көн тик утырырга тиеш. [6] Ир яки кыз бала тапканнан соң, чистарыну көннәре тәмамлангач, ул хатын тулаем яндыру корбаны өчен бер яшьлек бәрән һәм гөнаһ йолу корбаны өчен бала күгәрчен яки урман күгәрчене алып, Изге чатырга керү урыны алдына руханига китерсен. [7] Рухани, ул хатын кан китүдән чистарынсын өчен, корбаннарны Раббы алдында тәкъдим итсен. Шулай итеп, ул хатын кан агу нәҗеслегеннән чистарыныр. Ир яки кыз бала тудырган хатын өчен канун менә шундый.

[8] Әгәр дә хатынның бәрән алып килерлек хәле булмаса, ул, берсен тулаем яндыру корбаны, ә икенчесен гөнаһ йолу корбаны итеп, ике урман күгәрчене яки ике бала күгәрчен китерсен. Шул рәвешле, рухани, ул хатын кан китүдән чистарынсын өчен, шул корбаннарны тәкъдим итәр, һәм ул хатын чиста булыр».

*Тире авыруы турындагы канун*

**13** [1] Раббы Мусага һәм Һарунга болай диде:
[2] – Әгәр берәр кешенең тән тиресендә шеш яки тимгел, яисә җилсенү хасил булса һәм аның йогышлы тире авыруына әйләнү ихтималы булса, ул кеше рухани Һарунга яки аның угылларының берәрсенә – руханига китерелергә тиеш. [3] Рухани аның тәнендәге җәрәхәтне тикшерсен. Әгәр җәрәхәт өстендәге йоннар агарган һәм җәрәхәт тирәнгә киткән булса, бу – йогышлы тире авыруы билгесе. Рухани, аны тикшереп, нәҗес дип игълан

---

* **12:4** *Чистарыну* – яһүд дине буенча нәҗес кеше чистарынырга тиеш. Күрем күрү, бала тудыру һәм бүлендек нәҗеслегеннән чистарынганнан соң гына ул кеше чиста дип исәпләнә.

итсен. 4 Әгәр тән тиресендәге тимгел ак төстә булып, тире эченә
тирәнгә китмәгән һәм тимгел өстендәге йоннар агармаган булса,
рухани әлеге кешене җиде көнгә ябып куйсын. 5 Җиденче көнне
рухани аны тикшерсен; әгәр җәрәхәт элекке хәлендә калса һәм
тире өстендә җәелмәгән булса, рухани аны тагын җиде көнгә ябып
куйсын. 6 Җиденче көнне рухани аны тагын карасын һәм, җәрәхәт
азрак беленеп торса һәм тире өстендә җәелмәгән булса, рухани
аны чиста дип игълан итсен. Бу – бары тик тимгел генә; ул кеше
үзенең киемнәрен юарга тиеш, һәм ул чиста булыр. 7 Ләкин чиста-
рыну өчен руханига күренгәннән соң авыру кешенең тиресе өс-
тендә тимгел җәелә икән, ул икенче тапкыр руханига күренергә
тиеш. 8 Рухани, тимгелнең тире өстендә җәелүен күреп, аны нәҗес
дип игълан итсен: бу – йогышлы тире авыруы.
9 – Берәр кешедә йогышлы тире авыруы булса, ул руханига ки-
терелергә тиеш. 10-11 Рухани аны тикшерсен, һәм кешенең тәнендә-
ге шеше ак төстә булып, йоннары агарган һәм шеш тирәсендә яңа
җәрәхәт булса, бу – тән тиресендәге озакка сузыла торган йогыш-
лы тире авыруы; рухани аны нәҗес дип игълан итсен, әмма аны
ябып куярга боермасын, чөнки ул – нәҗес. 12-13 Әгәр авыру тире
өстендә җәелеп, бу кешене башыннан аягына кадәр капласа һәм
рухани аның бөтен тәнен әлеге авыру каплаганын күрсә, бөтен тә-
не агарган булганлыктан, рухани аны чиста дип игълан итсен, чөн-
ки бу авыру – йогышсыз, һәм ул кеше – чиста. 14 Ә инде яңа җә-
рәхәте күренсә, ул нәҗес булыр. 15 Рухани, аңарда җәрәхәт күргәч,
ул кешене нәҗес дип игълан итсен; җәрәхәт – йогышлы тире авы-
руы билгесе, бу – нәҗес. 16 Әгәр җәрәхәт үзгәрсә һәм агарса, авыру
кеше руханига барырга тиеш. 17 Рухани аны тикшерсен һәм, әгәр
җәрәхәт агарган булса, рухани авыру кешене чиста дип игълан ит-
сен, димәк, ул – чиста.
18-19 – Әгәр кемнең дә булса тәнендә эренле шеш булып, ул тө-
зәлсә һәм шеш урынында ак төстәге шеш яисә аксыл ал төстәге
җилсенгән тимгел хасил булса, ул кеше руханига күренергә тиеш.
20 Рухани аны тикшерсен. Әгәр шеш яки җилсенгән тимгел тире ас-
тында булып, йоннары агарган булса, рухани аны нәҗес дип игъ-
лан итсен. Бу – чуан өстендә хасил булган йогышлы тире авыруы.
21 Әгәр рухани тимгел өстендәге йоннарның ак булмавын һәм аның
тире астына тирәнгә китмәгәнен күрсә, өстәвенә, төсе тонык бул-
са, рухани ул кешене җиде көнгә ябып куйсын. 22 Әгәр дә авыру
тире өстендә җәелсә, рухани аны нәҗес дип игълан итсен; чөнки
бу – йогышлы авыру. 23 Ә инде җилсенгән тимгел үз урынында
калса һәм артык җәелмәсә, бу – тимгелдән калган яра эзе генә,
һәм рухани аны чиста дип игълан итсен.
24-25 – Кемнең дә булса тиресе утта пешеп, ул урын аксыл ал
яки ак төстәге тимгел шикелле булса, рухани тимгел өстендәге

йоннарның үзгәргәнен һәм тимгелнең тире астына тирәнгә үтүен күрсә, бу – тиренең пешкән урынында хасил булган йогышлы тире авыруы; рухани ул кешене нәҗес дип игълан итсен; чөнки бу – йогышлы тире авыруы. [26] Әгәр рухани тимгел өстендәге йоннарның агармаганлыгын һәм тире астында түгеллеген күрсә, өстәвенә, төсе тонык булса, рухани ул кешене җиде көнгә ябып куйсын. [27] Җиденче көнне рухани аны кабат тикшерсен һәм, әгәр тимгел тире өстендә җәелгән булса, рухани аны нәҗес дип игълан итсен, чөнки бу – йогышлы тире авыруы. [28] Әгәр дә инде тимгел үз урынында калса һәм тире өстендә җәелмәсә, өстәвенә, төсе тонык булса, бу – утта пешкәнлектән хасил булган яра эзе. Рухани аны чиста дип игълан итсен, чөнки бу – утта пешүдән калган яра эзе генә.

[29-30] – Әгәр берәр ир-ат яки хатын-кызның башында яки иягендә җәрәхәт булса, рухани ул җәрәхәтне карасын. Җәрәхәт тире астына тирәнгә үтеп, йоннары саргылт һәм нәзек булса, рухани аны нәҗес дип игълан итсен, чөнки бу – таз. Бу – йогышлы тире авыруы. [31] Әгәр рухани җәрәхәтне тикшереп, аның тире астына тирәнгә китмәвен һәм өстендәге йоннарның кара төстә булмавын күрсә, ул бу кешене җиде көнгә ябып куйсын. [32-33] Җиденче көнне рухани аны кабат тикшерсен; әгәр таз тәнгә җәелмәсә һәм аның өстендә саргылт йоннар булмаса, таз тире астына тирәнгә китмәсә, андый авыруның чәчен кыркырга, әмма таз урынына тимәскә кирәк. Шуннан соң рухани ул кешене икенче мәртәбә җиде көнгә ябып куйсын. [34] Җиденче көнне рухани тазны карасын; әгәр таз тәндә җәелмәгән һәм тире астына тирәнгә китмәгән булса, рухани аны чиста дип игълан итсен; ул кеше үзенең киемнәрен юарга тиеш, һәм ул чиста булыр. [35-36] Ләкин чистарынганнан соң әлеге кешенең тәнендәге тазы җәелеп китсә, рухани аны тагын тикшерсен; әгәр таз тәнгә җәелсә, саргылт йон эзләргә кирәкми; бу кеше – нәҗес. [37] Әгәр дә рухани, таз элекке хәленә керә һәм аның өстендә кара төстәге йон күренә, дип уйлый икән, таз авыруы төзәлгән була, димәк, ул кеше чиста; рухани аны чиста дип игълан итсен.

[38-39] – Әгәр берәр ир-ат яки хатын-кызның тәнендә ак тимгелләр булса, рухани аны тикшерсен; тимгелләр аксыл-тонык булса, бу – тире өстендә барлыкка килгән йогышсыз тимгелләр генә; ул кеше – чиста.

[40] – Кемнең дә булса башында чәче коелса, ул – пеләш башлы; ул кеше – чиста. [41] Әгәр башының алгы өлешендә чәче коелса, бу кеше – пеләш башлы; ул – чиста. [42] Ә инде пеләш яки чәчсез өлешендә аксыл ал төстәге тимгел күренсә, аның пеләшендә яки чәчсез өлешендә йогышлы тире авыруы барлыкка килгән була. [43-44] Рухани аны тикшерсен; әгәр кешенең пеләшендә яки чәчсез өлешендә җәрәхәт шеше аксыл ал төстә һәм ул кыяфәте белән тәндәге йогышлы тире авыруына охшаш булса, ул – йогышлы тире

авырулы кеше: ул – нәҗес; андый кешене рухани нәҗес дип игъ-
лан итсен, чөнки аның башында йогышлы тире авыруы бар.
45 – Йогышлы тире авырулы кеше ертылган киемнәр кияргә һәм
чәчен тузгытып, йөзенең аскы өлешен каплап: «Нәҗес! Нәҗес!» –
дип кычкырып йөрергә тиеш. 46 Авыруы төзәлгәнче, ул кеше нә-
җес булып, тукталу урынының тышында ялгызы гына, аерым яшәр-
гә тиеш.

*Кием-салымдагы күгәрек турындагы канун*

47-49 – Йон яки җитен кием, җитеннән яисә йоннан тегелгән яки
тукылган тукыма, күн яки күннән эшләнгән нинди дә булса әйбер
күгәрекле һәм ул күгәрек яшькелт яки кызгылт төстә булса, бу –
җәелә торган күгәрек; ул руханига күрсәтелергә тиеш. 50 Рухани
аны тикшерсен һәм күгәрекле әйберне җиде көнгә аерып бикләп
куйсын. 51 Җиденче көнне рухани аны тагын тикшерсен, һәм, әгәр
күгәрек киемгә, тегелгән яки тукылган тукымага, яки күннән эш-
ләнгән нинди дә булса әйбергә җәелгән булса, бу – нәҗес һәм за-
рарлы күгәрек. 52 Рухани күгәрекле ул киемне, җитеннән яисә йон-
нан тегелгән яки тукылган тукыманы, яки күннән эшләнгән нин-
ди дә булса әйберне яндырсын, чөнки бу – зарарлы күгәрек; ул
утта яндырылырга тиеш.
53-54 – Әгәр дә рухани әлеге киемдә, тегелгән яки тукылган ту-
кымада, яки күннән эшләнгән нинди дә булса әйбердә күгәрекнең
җәелмәгәнен күрсә, ул күгәрекле әйберне юарга әмер бирсен һәм
аны тагын җиде көнгә бикләп куйсын. 55 Күгәрекле әйберне юган-
нан соң, рухани аны тагын тикшерсен; әгәр күгәрекнең күренеше
үзгәрмәсә, аның җәелмәвенә карамастан, бу әйбер – нәҗес. Күгә-
рек аның эчендәме, тышындамы – барыбер, ул яндырылырга тиеш.
56 Әйберне юганнан соң рухани күгәрекнең тоныклануын күрсә, ул
күгәрек булган урынны киемнән, күннән яисә тегелгән, яки ту-
кылган тукымадан ертып алсын. 57 Әгәр күгәрек тагын килеп чык-
са, ул җәелә; күгәрекле әйбер яндырылырга тиеш. 58 Әгәр әйберне
юганнан соң күгәрек беткән икән, ул әйбер икенче мәртәбә юы-
лырга тиеш; шуннан соң ул чиста булыр.
59 Күгәрекле йон яки җитен киемне, тегелгән яки тукылган ту-
кыманы, күннән эшләнгән нинди дә булса әйберне нәҗес яки
чиста дип игълан итү хакындагы канун менә шушы.

*Йогышлы тире авыруыннан чистарыну турындагы канун*

**14** 1 Раббы Мусага болай диде:
2 – Йогышлы тире авыруы булган кешене авыруыннан
чистарту кануны менә шундый: чистарынасы көнне авы-
ру кеше руханига китерелсен. 3-4 Рухани, тукталу урыныннан читкә
чыгып, аны тикшерсен; әгәр йогышлы тире авыруының төзәлгән

булуын күрсә, ул чистарынучы кешегә тере ике чиста кош, эрбет
агачы, җете кызыл җеп һәм һүссөп үсемлеге китерергә кушсын.
[5] Рухани бу кошларның берсен балчык савыттагы саф чишмә суы
өстендә суярга әмер бирсен. [6] Ә ул үзе икенче тере кошны, эрбет
агачын, җете кызыл җепне, һүссөп үсемлеген алып, барысын бергә
саф су өстендә суелган кошның канына манчып алсын. [7] Аннары
йогышлы тире авыруыннан чистарынучы кешегә шуны җиде мәр-
тәбә сипсен һәм аны чиста дип игълан итсен, ә тере кошны ялан-
га очыртып җибәрсен.

[8] – Чистарынучы кеше үзенең киемнәрен юарга, барлык йонна-
рын кырырга, үзе су белән юынырга тиеш, аннары ул чиста булыр.
Шуннан соң ул тукталу урынына керсен, әмма җиде көн буе үз ча-
тырының тышында яшәсен. [9] Җиденче көнне ул тагын башындагы
бөтен чәчен, сакалын, кашларын һәм тәнендәге барлык йоннарын
кырырга, киемнәрен юарга һәм үзе су белән юынырга тиеш; шун-
нан соң ул чиста булыр.

[10] – Сигезенче көнне ул кимчелексез ике тәкә бәрән, кимчелексез
бер яшьлек саулык бәрән һәм, икмәк бүләге итеп, зәйтүн мае ку-
шылган, бер епаның уннан өч өлеше кадәр иң яхшы бодай оны һәм
бер лог* зәйтүн мае китерергә тиеш. [11] Чистартучы рухани чистары-
нучы кешене әлеге бүләкләре белән бергә Изге чатырга керү урыны
алдына Раббы каршына алып килсен. [12] Рухани, тәкә бәрәннәрнең
берсен, гаеп йолу корбаны итеп, бер лог май белән бергә китерсен
һәм аларны, махсус бүләк итеп, Раббы алдында селкетсен. [13] Ул гө-
наһ йолу корбаны һәм тулаем яндыру корбаны чалына торган изге
урында тәкә бәрәнне чалсын; гаеп йолу корбаны да, гөнаһ йолу
корбаны кебек үк, руханиныкы; бу – тулысынча изге корбан. [14] Ру-
хани гаеп йолу корбанының берникадәр канын алып, аны чистары-
нучы кешенең уң колак яфрагына, уң кулының һәм уң аягының
баш бармакларына сөртсен. [15] Рухани, берникадәр зәйтүн мае алып,
аны үзенең сул кулы учына салсын. [16] Шуннан соң рухани, уң бар-
магын сул кулы учындагы майга манчып, Раббы алдында бармагы
белән җиде мәртәбә шул майның бер өлешен сипсен. [17] Учында кал-
ган майның бер өлешен чистарынучы кешенең уң колак яфрагына,
уң кулының һәм уң аягының баш бармакларына, шулай ук гаеп йо-
лу корбанының канын сөрткән урыннарга сөртсен. [18] Рухани учын-
дагы майның калганын чистарынучы кешенең башына түксен һәм
Раббы алдында аны нәҗеслегеннән чистартсын.

[19] – Рухани, чистарынучы кеше үзенең нәҗеслегеннән чистарын-
сын өчен, гөнаһ йолу корбанын тәкъдим итсен, аннары тулаем ян-
дыру корбанын чалсын. [20] Шуннан соң рухани тулаем яндыру кор-
банын һәм икмәк бүләген мәзбәхкә куйсын. Рухани моны ул кеше

* **14:10** *Лог* – 0,5 литр чамасы.

үзенең нәҗеслегеннән чистарынсын өчен башкарыр, һәм ул кеше
чиста булыр.
21-22 – Әгәр ул кеше ярлы булып, гадәти корбаннарны китерер-
лек хәле булмаса, ул, үз нәҗеслегеннән чистарынсын өчен, гаеп
йолу корбаны итеп, бер тәкә бәрәнне Раббы алдына махсус бүләк
итеп китерсен. Ул, икмәк бүләге итеп, зәйтүн мае кушылган, бер
епаның уннан бер өлеше кадәр иң яхшы бодай оны, бер лог зәй-
түн мае һәм, хәленнән килгәнчә, ике урман күгәрчене яки ике ба-
ла күгәрчен китерсен; кошларның берсе – гөнаһ йолу корбаны,
икенчесе – тулаем яндыру корбаны булыр. 23 Ул, үзенең чистары-
нуы өчен, аларны сигезенче көнне руханига, Изге чатырга керү
урыны алдына Раббы каршына китерсен. 24 Рухани, гаеп йолу кор-
баны булган бәрәнне һәм бер лог майны алып, аларны махсус бү-
ләк буларак, Раббы алдында селкетсен. 25 Рухани бәрәнне чалсын
һәм, аның берникадәр канын алып, чистарынучы кешенең уң ко-
лак яфрагына, уң кулының һәм уң аягының баш бармакларына
сөртсен. 26-27 Шуннан соң рухани зәйтүн маеның бер өлешен сул
кулы учына салып, беразын уң кулының бармагы белән алсын да,
аны җиде мәртәбә Раббы алдында сипсен. 28 Рухани учында булган
майны чистарынучы кешенең уң колак яфрагына, уң кулының һәм
уң аягының баш бармакларына, шулай ук гаеп йолу корбанының
канын сылаган урыннарга сөртсен. 29 Үзенең учында калган майны
рухани, чистарынучы кеше үзенең нәҗеслегеннән чистарынсын
өчен, Раббы алдында аның башына түксен. 30-31 Аннары чистары-
нучы кеше, хәленнән килгәнчә, урман күгәрченнәренең яки бала
күгәрченнәрнең берсен – гөнаһ йолу корбаны, ә икенчесен тулаем
яндыру корбаны итеп, икмәк бүләге белән бергә китерсен. Шул
рәвешле, рухани, чистарынучы кеше үзенең нәҗеслегеннән чиста-
рынсын өчен, Раббы алдында күгәрченнәрне корбан итәр.
32 Чистарыну вакытында гадәти корбаннарны китерерлек хәле бул-
маган йогышлы тире авырулы кеше хакындагы канун менә шул.

### *Йорттагы күгәрек турындагы канун*

33 Раббы Мусага һәм Һарунга болай диде:
34 – Мин сезгә биләмә итеп бирәчәк Кәнган җиренә кергәч, йорт-
ларыгызның берсенә җәелә торган күгәрек җибәрсәм, 35 ул йортның
хуҗасы, рухани янына барып: «Минем өемдә җәелә торган күгә-
рек кебек нәрсә күренде», – дип әйтергә тиеш. 36 Рухани, өй эчен
тикшергәнче, өй эчендәге әйберләр нәҗес дип игълан ителмәсен
өчен, аларны тышкы якка чыгарырга әмер бирсен. Әйберләр чы-
гарылгач кына рухани өйне килеп тикшерсен. 37-38 Ул диварлар-
дагы күгәрекне тикшерсен. Әгәр өйнең диварларында яшькелт
яки кызгылт таплар күренсә һәм ул таплар диварны уеп кергән
булса, рухани өйдән чыксын һәм өйне җиде көнгә бикләп куйсын.

39-40 Җиденче көнне рухани тагын килеп, күгәрекнең җәелгән булуын күрсә, ул күгәрек булган ташларны кубарырга һәм аларны шәһәрдән алып чыгып, нәҗес урынга түгәргә әмер бирсен. 41 Шулай ук өйнең бөтен эчен кырып чистартырга һәм кырганда барлыкка килгән бөтен чүп-чарны шәһәрдән алып чыгып, шул ук урынга түгәргә боерсын. 42 Шуннан соң башка ташлар алып, ыргытылган ташлар урынына куйсыннар һәм, яңа измә алып, өйне сыласыннар.

43-44 – Ташларын кубарып, өйнең диварларын кырганнан һәм сылаганнан соң да күгәрек күренсә, рухани килеп карасын. Әгәр өйдә күгәрек җәелгән булса, бу өйдә зарарлы күгәрек бар, ул өй – нәҗес. 45 Андый өй җимерелергә тиеш, һәм аның ташлары, агачлары һәм бөтен измәсе шәһәрдән чыгарылып, нәҗес урынга түгелергә тиеш.

46 – Бикләп куелган өйгә кергән кеше кичкә кадәр нәҗес булыр; 47 һәм ул өйдә йоклаган кеше дә, шулай ук анда ашаган кеше дә үзенең киемнәрен юарга тиеш.

48 – Әгәр өйне сылаганнан соң, рухани өйдә күгәрекнең җәелмәгән булуын күрсә, ул бу өйне чиста дип игълан итсен; чөнки күгәрек узган була. 49-50 Ул өйне чистарту өчен рухани ике кош, эрбет агачы, җете кызыл җеп һәм һүссөп үсемлеге алып, бер кошны балчык савыттагы саф чишмә суы өстендә суйсын. 51 Эрбет агачын, һүссөп үсемлеген, җете кызыл җепне һәм тере кошны алып, аларны суелган кошның канына һәм саф суга манчып алып, шуның белән җиде тапкыр өйгә сипсен. 52 Шулай итеп, кош каны, саф су, тере кош, эрбет агачы, һүссөп үсемлеге һәм җете кызыл җеп белән рухани өйне чистартыр. 53 Тере кошны шәһәрдән алып чыгып, яланга очыртып җибәрсен. Шул рәвешле, рухани моны ул йорт нәҗеслектән арынсын өчен башкарыр, һәм ул йорт чиста булыр.

54-56 Бу – һәртөрле йогышлы тире авыруы, таз, шеш, тимгел һәм җилсенү, шулай ук кием-салымдагы һәм йорттагы күгәрек турындагы канун. Кем яки нәрсә кайчан нәҗес, кайчан чиста дип хәл ителсен өчен, йогышлы тире авыруы һәм күгәрек турындагы канун менә шул.

*Бүлендек нәҗеслеге турындагы канун*

**15** 1 Раббы Мусага һәм Һарунга болай диде:
2-3 – Исраиллеләргә игълан итегез: «Әгәр берәр ир кеше, авырып, бүлендек бүлеп чыгара икән, ул кеше нәҗес була. Аның тәненнән бүлендек агып яки тәнендә җыелып торса, бу аны нәҗесли*. 4 Бүлендекле кеше яткан урын-җир һәм ул утырган һәр нәрсә нәҗес булыр. 5 Аның урын-җиренә кагылган һәркем үзенең киемнәрен юарга һәм үзе дә су белән юынырга тиеш; урын-җиргә

* 15:2-3 12:4нче аятьтәге искәрмәне карагыз.

кагылган ул кеше кичкә кадәр нәҗес булыр. 6 Бүлендекле кеше
утырган берәр әйбергә бүтән кеше утырса, ул үзенең киемнәрен
юарга һәм үзе дә су белән юынырга тиеш, һәм ул кичкә кадәр нә-
җес булыр. 7 Әгәр кем дә булса берәү бүлендекле кешенең тәненә
кагылса, ул үзенең киемнәрен юарга һәм үзе дә су белән юынырга
тиеш, һәм ул кичкә кадәр нәҗес булыр. 8 Бүлендекле кеше чиста
кешегә төкерә икән, әлеге кеше үзенең киемнәрен юарга һәм үзе дә
су белән юынырга тиеш, ул кичкә кадәр нәҗес булыр. 9 Бүлендек-
ле кеше атланып барган ат өстендәге ияр кичкә кадәр нәҗес бу-
лыр. 10 Ул утырган нинди дә булса әйбергә кагылган һәркем кичкә
кадәр нәҗес булыр; һәм ул әйберләрне ташыган кеше үзенең ки-
емнәрен юарга һәм үзе дә су белән юынырга тиеш, һәм ул кичкә
кадәр нәҗес булыр. 11 Бүлендекле кеше кулын су белән юмаган ки-
леш кемгә дә булса кагыла икән, әлеге кеше үзенең киемнәрен
юарга һәм үзе дә су белән юынырга тиеш, һәм ул кичкә кадәр нә-
җес булыр. 12 Бүлендекле кеше кагылган балчык савыт ватылырга,
ә ул кагылган агач савыт су белән юылырга тиеш.

13 Берәр кеше бүлендек авыруыннан арынгач, җиде көн буе чис-
тарынырга тиеш; соңыннан үзенең киемнәрен юарга һәм тәнен саф
чишмә суы белән юарга тиеш, һәм ул чиста булыр. 14 Сигезенче
көнне ул, ике урман күгәрчене яки ике бала күгәрчен алып, Изге
чатырга керү урыны алдына Раббы каршына килергә һәм аларны
руханига бирергә тиеш. 15 Рухани ул кошларның берсен – гөнаһ
йолу корбаны, икенчесен исә тулаем яндыру корбаны итеп тәкъ-
дим итсен. Шул рәвешле, рухани моны әлеге кеше үзенең бүлен-
дек нәҗеслегеннән чистарынсын өчен Раббы алдында башкарыр.

16 Әгәр берәүдән орлык бүленеп чыга икән, ул кеше үзенең бө-
тен тәнен су белән юарга тиеш, һәм ул кичкә кадәр нәҗес булыр.
17 Орлык тигән һәр кием, һәр күн су белән юылырга тиеш, һәм
ул әйберләр кичкә кадәр нәҗес булыр. 18 Әгәр берәр ир кеше ха-
тын-кыз белән ятканда орлык бүленеп чыга икән, алар икесе дә су
белән юынырга тиешләр, һәм алар кичкә кадәр нәҗес булырлар.

19 Әгәр берәр хатын-кызның гадәттәге күрем күрү вакыты икән,
ул җиде көн нәҗес булыр. Бу вакытта ул хатынга кагылган һәр ке-
ше кичкә кадәр нәҗес булыр. 20 Хатын-кыз нәҗес чагында яткан
һәр урын-җир, утырган һәр нәрсә нәҗес булыр. 21-23 Ул хатынның
урын-җиренә яки ул хатын утырган һәр нәрсәгә кагылган кеше
үзенең киемнәрен юарга һәм үзе дә су белән юынырга тиеш, һәм
ул кичкә кадәр нәҗес булыр. 24 Әгәр ул хатынның ире аның белән
ятканда, хатынның каны иренә тисә, ул ир җиде көн буе нәҗес
булыр, һәм ул ир яткан урын-җир дә нәҗес булыр.

25 Әгәр берәр хатын-кызның гадәттәге күрем күрү вакытыннан
тыш каны килеп торса яки гадәттәге күрем күрү вакытыннан соң да
кан килүе дәвам итсә, ул, гадәттәге кан килү вакытындагы кебек,

нәҗес булыр. Каны килеп торганда, ул хатын — нәҗес. [26] Каны ак-
кан бөтен вакыт дәвамында ул яткан урын-җир, гадәттәге күрем
күрү вакытындагы кебек үк, нәҗес булыр, һәм ул утырган һәр
нәрсә, гадәттәге кан килү вакытындагы кебек, нәҗес булыр. [27] Ул
әйберләргә кагылган һәркем нәҗес булыр, һәм ул кеше үзенең ки-
емнәрен юарга һәм үзе дә су белән юынырга тиеш, һәм ул кичкә
кадәр нәҗес булыр. [28] Кан агуы туктаганнан соң, ул хатын җиде көн
буе чистарынырга тиеш, һәм шуннан соң ул чиста булыр. [29] Сиге-
зенче көнне ул ике урман күгәрчене яки ике бала күгәрчен алып,
аларны Изге чатырга керү урыны алдына руханига китерергә ти-
еш. [30] Рухани ул кошларның берсен — гөнаһ йолу корбаны, икен-
чесен тулаем яндыру корбаны итеп тәкъдим итсен. Шул рәвешле,
рухани моны ул хатын үзенең бүлендек нәҗеслегеннән чистарын-
сын өчен Раббы алдында башкарыр».

[31] — Сез, Минем исраиллеләр арасындагы торагымны нәҗесләмичә, Исраил кешеләре үз нәҗеслекләре эчендә һәлак булмасын өчен, аларны нәҗеслектән сакларга тиеш.

[32-33] Бүлендекле яки орлык агызудан нәҗесләнгән ир-ат, гадәттәге күрем күрүче хатын-кыз, бүлендекле ир-ат яки хатын-кыз һәм нәҗес хатын белән якынлык кылган ир кеше турындагы канун менә шушы.

*Гөнаһ йолу көне*

**16** [1-2] Һарунның ике угылы Раббы алдына якынаеп үлгәннән соң, Раббы Мусага болай дип әйтте:
— Абыең Һарунга әйт: ул вакытлы-вакытсыз Иң изге бүлмәгә*, пәрдә артына, Аллаһы сандыгы* өстендәге гөнаһ йолу урынына* кермәсен, чөнки Мин болыт эчендә гөнаһ йолу урыны өстендә пәйда булырмын; югыйсә ул үләчәк.

[3] — Шуңа күрә, Һарун Иң изге бүлмәгә кергәндә, гөнаһ йолу корбаны итеп, бер үгез бозау һәм, тулаем яндыру корбаны итеп, бер сарык тәкәсе китерергә тиеш. [4] Ул җитеннән тегелгән ыштанны эчтән киеп, изге җитен күлмәкне кисен; аннары билен җитен пута белән

---

* 16:1-2 *Иң изге бүлмә* — Изге чатыр эчендәге ике бүлмәнең берсе. Бу бүлмә Изге бүлмәдән зур пәрдә белән аерып алынган һәм анда Аллаһы сандыгы куелган булган (карагыз: «Чыгыш» китабы 26:33-34).

* 16:1-2 *Аллаһы сандыгы* — Изге чатырдагы Иң изге бүлмәдә торган. Аның эчендә Аллаһының ун боерыгы язылган таш такталар сакланган (карагыз: «Чыгыш» китабы 25:10-16).

* 16:1-2 *Гөнаһ йолу урыны* — Аллаһы сандыгының капкачы. Сандык өстенә күктәге канатлы затларның сыннары куелган булган, аларның канатларыннан төшкән күләгә гөнаһ йолу урынын каплап торган (карагыз: «Чыгыш» китабы 25:17-22).

буып, башына җитен тюрбан кисен. Болар – изге киемнәр. Болар-
ны кигәнче, ул су белән юынырга тиеш.
5 – Гөнаһ йолу корбаны итеп, Һарун Исраил халкыннан ике кә-
җә тәкәсе һәм, тулаем яндыру корбаны итеп, бер сарык тәкәсе ал-
сын. 6 Ул, үзе һәм гаиләсе гөнаһтан арынсын өчен, үзенең гөнаһ
йолу корбаны итеп үгез бозау тәкъдим итсен. 7 Аннары ул ике кәҗә
тәкәсе алып, аларны Изге чатырга керү урыны алдына Раббы кар-
шына китерсен. 8 Шуннан соң Һарун ике кәҗә тәкәсенә жирәбә
салсын: берсен – Раббыга, икенчесен – Азазелга*. 9 Ул, жирәбә
Раббыга китерергә дип төшкән кәҗә тәкәсен алып, аны гөнаһ йо-
лу корбаны итеп тәкъдим итсен. 10 Ә инде Азазелга җибәрергә дип
жирәбә төшкән кәҗә тәкәсен, халыкның гөнаһларын алып китсен
дип, чүлгә Азазелга җибәрү өчен, тере килеш Раббы алдына куйсын.
11 – Һарун, үзе һәм гаиләсе гөнаһтан арынсын өчен, үзенең гөнаһ
йолу корбаны булган үгез бозауны китереп, аны суйсын. 12 Ул, сумала
төтәсләү савытын алып, Раббы алдындагы мәзбәхтән утлы күмер
һәм, ике учын тутырып, төеп вакланган хуш исле сумала алсын да
пәрдә артына кертсен. 13 Ул, боерыклар сандыгы өстендәге гөнаһ йо-
лу урынын хуш исле сумала болыты капласын дип, Раббы алдында
сумаланы ут өстенә куйсын. Шулай эшләгәндә генә ул үлми калачак.
14 Һарун, үгез бозауның берникадәр канын алып, бармагы белән гө-
наһ йолу урынының алгы ягы өстенә сипсен һәм бармагы белән гө-
наһ йолу урынының алдына янә җиде мәртәбә сипсен.
15 – Шуннан соң Һарун, халык өчен гөнаһ йолу корбаны булган
кәҗә тәкәсен суеп, аның канын пәрдәнең артына алып керсен һәм
аның каны белән дә үгез бозау каны белән эшләгән кебек эшлә-
сен: аны гөнаһ йолу урынының өстенә һәм аның алдына сипсен.
16 Шул рәвешле, ул Иң изге бүлмәне исраиллеләрнең нәҗеслегеннән-
нән һәм җинаятьләреннән – аларның бөтен гөнаһларыннан чис-
тартыр. Ул Изге чатыр белән дә шулай эшләсен, чөнки бу чатыр
аларның нәҗеслекләре арасында урнашкан. 17 Һәммәсе нәҗеслектән
чистарынсын өчен, Һарун Иң изге бүлмәгә, кергән вакыттан алып
аннан чыкканчы, ул үзе, үзенең гаиләсе һәм барча Исраил халкы
гөнаһтан арынганчы, Изге чатырда бер кеше дә булмаска тиеш.
18 – Шуннан соң Һарун, Раббы алдындагы мәзбәх янына чыгып,
аны нәҗеслектән чистартсын; үгез бозау канының бер өлешен һәм
кәҗә тәкәсенең берникадәр канын алып, мәзбәхнең барлык мө-
гезләренә сөртсен. 19 Бармагы белән аларның берникадәр канын
алып, җиде мәртәбә мәзбәх өстенә сипсен. Шулай итеп, ул аны
чистартыр һәм, исраиллеләрнең нәҗеслегеннән арындырып, аны
изгеләндерер.

---

* 16:8 *Азазел* – яһүдчә әлеге сүзнең мәгънәсе аңлаешсыз. Ахрысы, бу чүл-
дәге бер җен исемен аңлата.

[20] – Иң изге бүлмәне, Изге чатырны һәм мәзбәхне чистарткан-
нан соң, Һарун тере кәҗәне алып килсен. [21] Үзенең ике кулын тере
кәҗәнең башына куеп, аның өстендә исраиллеләрнең барлык хә-
сислекләрен һәм җинаятьләрен – аларның бөтен гөнаһларын танып
сөйләсен һәм шул гөнаһларны кәҗәнең башы өстенә куеп, кәҗәне
чүлгә билгеләнгән бер кеше белән чыгарып җибәрсен. [22] Кәҗә ха-
лыкның барлык гөнаһларын кешесез җирләргә үз өстендә алып
китәр. Әлеге билгеләнгән кеше аны чүлгә җибәрсен.
[23] – Шуннан соң Һарун, Изге чатырга кереп, Иң изге бүлмәгә
кергәндә кигән, җитеннән әзерләнгән киемнәрне салып, анда кал-
дырсын. [24] Ул изге урында үзенең тәнен су белән юып, гадәти
киемнәрен кисен һәм аннан чыгып, үзе һәм бөтен халык гөнаһтан
арынсын өчен, үзенең һәм халыкның тулаем яндыру корбаннарын
тәкъдим итсен. [25] Шуннан соң гөнаһ йолу корбаны булган хайван-
нарның маен мәзбәхтә яндырсын.
[26] – Азазелга җибәргән кәҗәне чүлгә алып барган кеше үзенең
киемнәрен һәм тәнен су белән юарга тиеш, шуннан соң ул тукталу
урынына керә алыр. [27] Гөнаһ йолу корбаны булган үгез бозау һәм
кәҗә тәкәсе тукталу урыныннан читкә чыгарылып, аларның тире-
се, ите һәм эчендәге шакшылары утта яндырылырга тиеш, чөнки,
гөнаһ йолу өчен, аларның каннары Иң изге бүлмәгә китерелде.
[28] Аларны яндырган кеше үзенең киемнәрен һәм тәнен су белән
юарга тиеш; шуннан соң гына ул тукталу урынына керә алыр.
[29] – Менә болар сезнең өчен мәңгелек кагыйдә: җиденче айда,
айның унынчы көнендә ураза тотыгыз; җирле кешеме ул яисә сез-
нең арагызда яшәүче читтән килгән кешеме, бу көнне бернәрсә дә
эшләмәскә тиеш. [30] Ул көнне, барлык гөнаһларыгыздан арындыру
өчен, гөнаһтан арындыру эшләре башкарылсын; соңыннан сез
Раббы алдында чиста булырсыз. [31] Бу – сезнең өчен махсус ял кө-
не, сез ураза тотарга тиеш; бу – мәңгелек кагыйдә. [32-33] Атасыннан
соң аның урынына билгеләнгән һәм майланган Баш рухани чис-
тарту эшләрен башкарсын. Ул, изге җитен киемнәр киеп, Иң изге
бүлмә, Изге чатыр, мәзбәх, руханилар һәм барлык халык нәҗес-
лектән чистарынсын өчен, чистарту эшләре башкарсын. [34] Менә
бу сезгә мәңгелек кагыйдә: елына бер мәртәбә, исраиллеләр бар-
лык гөнаһларыннан арынсын өчен, шушы эшләр башкарылсын.
Раббы Мусага ничек әмер иткән булса, һәммәсе шулай эшләнде.

*Изге чатырдан читтә корбан чалуны һәм кан ашауны тыю*

**17** [1] Раббы, Мусага дәшеп, болай диде:
[2] – Һарунга, аның угылларына һәм барлык исраиллеләргә
игълан ит: «Раббы менә шундый әмер бирде: [3-4] Исраил
халкы арасыннан кем дә булса берәү тукталу урынында яки аның
тышында корбан итеп сыер, сарык яисә кәҗә чала икән һәм аны,

Раббы алдында корбан итеп, Изге чатырга керү урыны алдына, Раббы чатыры каршына китерми икән, ул кеше кан коючы дип исәпләнсен, чөнки ул кан түкте. Андый кеше үз халкыннан читләштерелергә тиеш. [5] Шуның өчен, исраиллеләр үз корбаннарын яланда чалмыйча, Изге чатырга керү урыны алдына, Раббы каршына, руханига китерсеннәр һәм татулык корбаны итеп тәкъдим итсеннәр. [6] Ә рухани исә канны Изге чатырга керү урыны янындагы Раббы мәзбәхенә чәчрәтсен һәм, хуш исен Раббы алдында чыгарырлык итеп, майны яндырсын. [7] Шуннан соң исраиллеләр, Раббыга тугры булып, үзләренең корбаннарын кәҗә кыяфәтендәге потларга китермәскә тиешләр. Бу – аларга һәм аларның киләчәк буыннарына мәңгелек кагыйдә».

[8-9] – Аларга тагы шуны игълан ит: «Исраиллеләрнең яисә алар арасында яшәүче читтән килгәннәрнең берәрсе тулаем яндыру корбаны яки башка бүләк китерсә һәм, аны Раббыга тәкъдим итеп, Изге чатырга керү урыны алдына китермәсә, андый кеше үз халкыннан читләштерелергә тиеш.

[10] Әгәр исраиллеләрнең яки алар арасында яшәүче читтән килгәннәрнең берәрсе кан ашый икән, Мин кан ашаучы кешегә каршы чыгачакмын һәм аны үз халкыннан читләштерәчәкмен. [11] Чөнки һәр тәннең җаны үзенең канында; шуңа күрә Мин, сезнең җаннарыгыз гөнаһыннан арынсын өчен, мәзбәхтә канны түгәргә куштым, кан җанны гөнаһтан арындыра. [12] Менә шуның өчен дә Мин исраиллеләргә болай дидем: „Сез үзегез дә, арагызда яшәүче читтән килгән бүтән кеше дә кан ашарга тиеш түгел“.

[13] Исраиллеләрнең яки алар арасында яшәүче читтән килгәннәрнең берәрсе ау вакытында ашарга яраклы хайван яки кош тота икән, ул аның канын агызып бетерергә һәм канны туфрак белән күмәргә тиеш. [14] Чөнки һәр тәннең җаны – аның канында; менә шуның өчен дә Мин исраиллеләргә: „Һичнинди тәннең канын ашамагыз, чөнки һәр тәннең җаны – канында, – дидем, – кан ашаган һәр кеше читләштерелергә тиеш“.

[15] Үзе үлгән яки ерткыч җанвар ботарлаган җәнлек итен ашаган теләсә кем – җирле кешеме ул яисә читтән килгән кешеме – үзенең киемнәрен юарга һәм үзе дә су белән юынырга тиеш, һәм ул кичкә кадәр нәҗес булыр, шуннан соң чиста булыр. [16] Әлеге кеше үзенең киемнәрен һәм тәнен юмаса, ул җәзага тартылырга тиеш».

### *Канунсыз якынлык кылуны тыю*

**18** [1] Раббы, Мусага дәшеп, болай диде:
[2] – Исраиллеләргә игълан ит: «Мин – Раббы Аллагыз.
[3] Сез яшәгән Мисыр җирендәгечә эш итмәгез, шулай ук Мин сезне алып барачак Кәнган җирендәгечә дә гамәл кылмагыз, аларның йолалары буенча яшәмәгез. [4] Минем кануннарымны һәм

кагыйдәләремне саклап, шулар белән гамәл кылыгыз. Мин – Раб-
бы Аллагыз. 5 Минем кагыйдәләремне һәм кануннарымны җиренә
җиткереп үтәгез, аларны үтәгән кеше исән булачак. Мин – Раббы.

6 Сезнең арагыздан беркем дә кыз кардәшенә якынаеп, аның бе-
лән якынлык кылырга тиеш түгел. Мин – Раббы. 7 Анаң белән якын-
лык кылып, үз атаңны хурлыкка төшермә. Ул – синең анаң, аның бе-
лән якынлык кылма. 8 Атаңны хурлыкка төшермә: үги анаң белән
якынлык кылма. 9 Үзеңнең бертуган кыз кардәшең, ягъни атаңның
кызы белән дә, анаңның кызы белән дә якынлык кылма. Аның
син яшәгән өйдә туган булу-булмавына карамастан, ул кыз кардәшең
белән якынлык кылма. 10 Үзеңне хурлыкка төшермә: кыз оныгың бе-
лән якынлык кылма. 11 Атаңның кызы – аның хатынының кызы
белән якынлык кылма, чөнки ул – синең кыз кардәшең. 12 Атаңның
кыз туганы белән якынлык кылма; ул – синең атаңның кан кардә-
ше. 13 Анаңның кыз туганы белән якынлык кылма, чөнки ул – си-
нең анаңның кан кардәше. 14 Атаңның бертуган абыйсын хурлыкка
төшермә: аның хатынына якынаеп, аның белән якынлык кылма, чөн-
ки ул – синең якын апаң. 15 Үз килененең белән якынлык кылма.
Ул – синең угылыңның хатыны, аның белән якынлык кылма. 16 Бер-
туганыңны хурлыкка төшермә: аның хатыны белән якынлык кыл-
ма. 17 Хатын алсаң, аның кызы яки кыз оныгы белән якынлык
кылма; алар хатыныңның кан кардәшләре; бу – хәсислек. 18 Хаты-
ның исән чакта, аңа көндәш булмасын өчен, аның бертуган сең-
лесен үзеңә хатын итеп алма һәм аның белән якынлык кылма.

19 Хатыныңның гадәттәге кан килү вакытында, аңа якынаеп, аның
белән якынлык кылма. 20 Иптәшеңнең хатыны белән якынлык
кылма; бу сине нәҗесләячәк. 21 Балаларыңның берсен дә Молых
илаһына корбан итмә, шуның белән Аллаңның исемен хур итмә.
Мин – Раббы. 22 Хатын-кыз белән якынлык кылган кебек, ир-ат
белән якынлык кылма; бу – кабахәтлек. 23 Нинди дә булса хайван бе-
лән якынлык кылма, шуның белән үзеңне нәҗесләмә. Хатын-кыз
да, хайван янына килеп, аның белән якынлык кылырга тиеш тү-
гел; бу – кабахәтлек.

24 Мондый эшләр белән үзегезне нәҗесләмәгез, чөнки сезнең
янызыздан Мин куып җибәрәчәк халыклар моңарчы шундый эш-
ләре белән үзләрен нәҗесләндерделәр инде. 25 Хәтта җир нәҗес-
ләнде; шуңа күрә Мин, аның халкының гөнаһы өчен, җирне җәза-
ладым, һәм җир үзендә яшәүчеләрне читкә какты. 26 Ә сез Минем
кагыйдәләремне һәм кануннарымны сакларга тиеш. Сез – җирле
кешеләр дә, сезнең арагызда яшәүче читтән килгәннәр дә – мон-
дый кабахәтлекләрне эшләргә тиеш түгел. 27 Чөнки мондый каба-
хәтлекләрне шушы җирдә яшәүчеләр эшләделәр инде, һәм шуның
нәтиҗәсендә, җир нәҗесләнде. 28 Әгәр җирне нәҗесләсәгез, бу
җир, сездән элек яшәгән халыкларны үзеннән кире каккан кебек,

сезне дә кире кагачак. [29] Әгәр кем дә булса берәү мондый кабахәт-
лекләрне эшли икән, ул кеше үз халкыннан читләштерелергә тиеш.
[30] Шуңа күрә Минем күрсәтмәләремне үтәгез, бу җирдә сездән
элек яшәгәннәрнең кабахәтлекләрен кабатламагыз һәм алар белән
үзегезне нәҗесләмәгез. Мин – Раббы Аллагыз».

*Дини һәм әхлакый тормыш турындагы кагыйдә*

**19** [1] Раббы Мусага болай диде:
[2] – Барча Исраил халкына игълан ит: «Изге булыгыз, чөн-
ки Мин – Раббы Аллагыз; Мин – изге. [3] Сезнең һәркай-
сыгыз үзенең ата-анасына хөрмәт күрсәтергә һәм Минем шимбә
көннәремне тотарга тиеш. Мин – Раббы Аллагыз.
[4] Сыннарга табынмагыз һәм үзегезгә коелма потлар ясамагыз.
Мин – Раббы Аллагыз.
[5] Әгәр Раббыга татулык корбаны тәкъдим итәсез икән, бу кор-
бан Раббы тарафыннан кабул ителсен дип китерегез. [6] Корбанның
ите корбан китерелгән көнне яки икенче көнне ашалып бетсен, ә
өченче көнгә калганы утта яндырылырга тиеш. [7] Әгәр кем дә булса
берәү аны өченче көнне ашый икән, бу нәҗеслек булыр, һәм Мин
корбанны кабул итмәячәкмен. [8] Аны ашаучы җәзага тартылырга
тиеш, чөнки ул Раббының изге әйберен нәҗесләде; андый кеше үз
халкыннан читләштерелергә тиеш.
[9] Иген кырыгызның уңышын җыйган вакытта читенә кадәр җит-
кереп урмагыз һәм урганнан калган башакларны кабат җыймагыз.
[10] Йөземне дә кабат җыймагыз һәм җиргә коелганнарын да алма-
гыз: аларны фәкыйрьләргә һәм читтән килеп урнашканнарга кал-
дырыгыз. Мин – Раббы Аллагыз.
[11] Урламагыз, ялганламагыз һәм иптәшегезне алдамагыз. [12] Ми-
нем исемем белән ялган ант итмәгез, шуның белән Аллагызның
исемен хурламагыз. Мин – Раббы.
[13] Якыныңны рәнҗетмә һәм талама. Ялчыңа хезмәт хакын тү-
ләүне икенче көнгә калдырма. [14] Чукракка яман телләнмә; абын-
сын дип, сукыр кешенең аягы астына әйбер куйма. Аллаңнан кур-
кып, Аны хөрмәт ит. Мин – Раббы.
[15] Хөкем иткәндә хаксыз булма; фәкыйрьнең хәтерен калдырма,
байның күңелен күрергә тырышма; үзеңнең иптәшеңне гадел хө-
кем ит. [16] Үз халкың арасында гайбәт сатып йөрмә. Якыныңның
тормышын куркыныч астына куйма. Мин – Раббы.
[17] Туганыңа карата күңелеңдә дошманлык саклама; иптәшеңне
шелтәлә һәм аның өчен гаепле булма. [18] Үз халкың арасында бер-
кемнән дә үч алма һәм аңа карата ачу тотма; якыныңны үзеңне
яраткан кебек ярат. Мин – Раббы.
[19] Минем кагыйдәләремне саклагыз: үзегезнең йорт хайваныгыз-
ны башка токым хайван белән кушылдырмагыз; бер үк кырыгызга

ике төрле үсемлек орлыгы чәчмәгез; ике төрле тукымадан тегелгән
кием кимәгез.
[20] Кем дә булса берәү башка иргә ярәшелгән кол хатын-кыз бе-
лән якынлык кылса, ул җария әлегә кадәр сатып алынмаган яки
әле азат ителмәгән булса, алар җәзага тартылырга тиеш; әмма
үлем җәзасына түгел, чөнки хатын азат түгел, ул җария генә.
[21] Әлеге ир кеше, Раббыга гаеп йолу корбаны бирү өчен, Изге ча-
тырга керү урыны алдына сарык тәкәсе алып килергә тиеш. [22] Һәм
рухани, ул кеше үзенең гөнаһыннан арынсын өчен, Раббы алдын-
да гаеп йолу корбанын тәкъдим итәр, һәм бу кешенең гөнаһы ки-
черелер.
[23] Кәнган җиренә килгәч, җимеш бирә торган нинди дә булса
агач утыртсагыз, аларның җимешен баштагы өч елда ашарга яра-
мый дип исәпләгез, чөнки аңарчы аларның җимеше ашарга ярак-
лы булмый, алар ашалырга тиеш түгел. [24] Ә инде дүртенче елда
аларның җимешләре изге булыр; бу – Раббыга шөкер итү бүләге.
[25] Бишенче елда исә сез аның җимешләрен ашый аласыз; шулай
итеп, сезнең уңышыгыз арткannан-арта барачак. Мин – Раббы
Аллагыз.
[26] Бернинди итне дә каны белән ашамагыз; күрәзәлек итмәгез,
сихер белән шөгыльләнмәгез. [27] Чигәләрегездәге чәчне кырыкма-
гыз, сакалыгызның кырыйларын кыркып бозмагыз. [28] Үлгән кеше
истәлегенә тәнегезгә бернинди яра да, тамга да ясамагыз. Мин –
Раббы.
[29] Кызларыгызны фахишә итеп нәҗесләмәгез; югыйсә, җир йөзе
фәхешлек һәм хәсислек белән тулачак. [30] Минем шимбә көннә-
ремне тотыгыз һәм Минем изге урынымны хөрмәт итегез. Мин –
Раббы.
[31] Үлгән кешеләрнең җаннарын чакыручыларга мөрәҗәгать ит-
мәгез, сихерчеләргә йөрмәгез; югыйсә, алар сезне нәҗесләячәк-
ләр. Мин – Раббы Аллагыз.
[32] Чәчләре агарган өлкән кеше алдында аягүрә басыгыз, карт ке-
шегә хөрмәт күрсәтегез һәм, Аллагыздан куркып, Аны хөрмәт ите-
гез. Мин – Раббы.
[33] Сез яшәгән җиргә килеп урнашкан чит кешене җәберләмәгез.
[34] Ул җирле кеше кебек үк исәпләнергә тиеш; аны үзегезне яраткан
кебек үк яратыгыз, чөнки сез үзегез дә Мисыр җирендә чит кеше
идегез. Мин – Раббы Аллагыз.
[35] Үлчәгәндә, озынлык, авырлык һәм микъдар үлчәмнәрендә
хаксызлык эшләмәгез. [36] Үлчәүләрегез, герләрегез һәм башка үлчәү
әсбапларыгыз дөрес булырга тиеш. Мин – Раббы Аллагыз, сезне
Мисыр җиреннән алып чыктым.
[37] Минем барлык кагыйдәләремне һәм кануннарымны саклап,
шулар белән гамәл кылыгыз. Мин – Раббы».

*Төрле гөнаһлар өчен җәза*

20 [1] Раббы Мусага болай диде:
[2] – Исраиллеләргә игълан ит: «Исраиллеләрнең яки алар
арасында яшәүче читтән килгәннәрнең берәрсе үз бала-
ларыннан берсен Молых илаһына бирә икән, ул кеше үлемгә тап-
шырылырга һәм халык аны ташлар белән кыйнап үтерергә тиеш.
[3] Мин андый кешегә каршы чыгачакмын һәм аны үз халкыннан
читләштерәчәкмен, чөнки ул, үзенең балаларын Молых илаһына
биреп, Минем изге урынымны нәҗесләде һәм Минем изге исемем-
не хур итте. [4] Әгәр халык үзенең балаларын Молых илаһына тап-
шырган андый кешегә игътибар юнәлтмәсә һәм аны юк итмәсә,
[5] Мин андый кешегә дә, аның гаиләсенә дә каршы чыгачакмын,
һәм аларны үз халкыннан читләштерәчәкмен; шулай ук, Молых
илаһына ияреп, әлеге кешенең артыннан баручыларны да читләш-
терәчәкмен.

[6] Әгәр кем дә булса берәү, Миңа тугры булмыйча, үлгән кеше-
ләрнең җаннарын чакыручыларга һәм сихерчеләргә мөрәҗәгать
итә икән, Мин андый кешегә каршы чыгачакмын һәм аны үз хал-
кыннан читләштерәчәкмен.

[7] Үзегезне изгеләндерегез һәм изге булыгыз, чөнки Мин – Раб-
бы Аллагыз. [8] Минем кагыйдәләремне саклагыз һәм үтәгез. Мин –
Раббы, сезне изге итүче.

[9] Үз атасына яки анасына яман теллеләнгән һәркем үлемгә тап-
шырылырга тиеш, чөнки ул атасына яки анасына яман сүзләр
әйтте; үлемендә ул үзе гаепле булыр.

[10] Кем дә булса берәү якынының хатыны белән зина кылса, зина
кылучы ир кеше дә, хатын да үлемгә тапшырылырга тиеш. [11] Кем
дә булса атасының хатыны белән якынлык кылса, ул үзенең ата-
сын хур итте; ул ир дә, хатын да үлемгә тапшырылырга тиеш; үз
үлемендә алар үзләре гаепле булыр. [12] Әгәр дә берәү үзенең килене
белән якынлык кылса, алар икесе дә үлемгә тапшырылырга тиеш.
Алар кабахәтлек эшләделәр; үз үлемендә алар үзләре гаепле булыр.
[13] Әгәр берәр ир-ат, хатын-кыз белән якынлык кылган кебек, икен-
че бер ир кеше белән якынлык кылса, алар икесе дә кабахәтлек
эшләделәр һәм үлемгә тапшырылырга тиешләр; үз үлемендә алар
үзләре гаепле булыр. [14] Әгәр нинди дә булса бер ир үз хатыны өс-
тенә аның анасын да хатын итеп ала икән, бу – хәсислек; сезнең
арагызда хәсислекләр булмасын өчен, ул ир дә, әлеге хатыннар да
яндырып үтерелергә тиешләр. [15] Кем дә булса берәү хайван белән
якынлык кыла икән, ул кеше үлемгә тапшырылырга һәм хайван да
үтерелергә тиеш. [16] Әгәр бер хатын нинди дә булса хайванга якы-
наеп, аның белән якынлык кыла икән, хатын да, хайван да үтере-
лергә тиеш; алар икесе дә үлемгә тапшырылырга тиеш; үз үлемендә

алар үзләре гаепле булыр. 17 Әгәр бер ир кеше кыз туганын – ата-
сының яки анасының кызын хатын итеп алса һәм аның белән
якынлык кылса, бу – хурлык; алар үз халкының күз алдыннан
читләштерелергә тиеш, чөнки әлеге кеше үзенең кыз туганын хур
итте; ул җәзага тартылырга тиеш. 18 Әгәр берәр кеше хатын-кыз-
ның гадәттәге күрем күрү вакытында аның белән якынлык кылса,
алар икесе дә нәҗеслектән арыну кануннарын бозган булып исәп-
ләнә, һәм алар икесе дә үз халыкларыннан читләштерелергә тиеш.
19 Ананның да, атаңның да кыз туганы белән якынлык кылма;
чөнки ул кеше үзенең кан кардәшен хур итә; ул ир кеше дә, ха-
тын да җәзага тартылырга тиеш. 20 Кем дә булса туган абыйсының
хатыны белән якынлык кыла икән, ул кеше үзенең абыйсын мәс-
хәрә итте; ул ир кеше дә, хатын да җәзага тартылырга тиеш. Алар
баласыз үләчәкләр. 21 Әгәр кем дә булса берәү бертуганының хаты-
нын ала икән, бу – нәҗеслек; андый кеше үзенең бертуганын хур
итте; ул ир кеше дә, хатын да баласыз булачаклар.

22 Минем барлык кагыйдәләремне дә, кануннарымны да саклап,
шулар белән гамәл кылыгыз; шулай эшләсәгез, Мин алып барачак
җир сезне кире какмас. 23 Арагыздан Мин куып җибәрәчәк халык-
ларның йолалары буенча яшәмәгез, чөнки алар бу кабахәтлекләр-
не эшләделәр инде, һәм шуның өчен Мин аларга бик нык ачулан-
дым. 24 Ә Мин исә сезгә әйттем: „Сез аларның җирләрен биләрсез;
сөт һәм бал ага торган ул җирне Мин сезгә мирас-биләмә итеп
бирәчәкмен“. Мин – Раббы Аллагыз, сезне барлык башка халык-
лардан аерып алдым.

25 Чиста хайванны да, чиста кошны да нәҗесеннән аера белегез.
Мин сезнең өчен нәҗес дип билгеләгән хайваннар, кошлар һәм
сөйрәлүчеләр белән үзегезне нәҗесләмәгез. 26 Сез Миңа изге булы-
гыз, чөнки Мин – Раббы, изге һәм, сез Минеке булсын дип, сезне
башка халыклардан аерып алдым.

27 Әгәр берәү, ир кешеме ул яки хатын-кызмы, үлгән кешеләр-
нең җаннарын чакыручы яисә сихерче булса, ул үлемгә тапшыры-
лырга тиеш: аны ташлар белән бәргәләгез; үз үлемендә ул үзе гаеп-
ле булыр».

### *Руханилар турындагы канун*

**21** 1 Раббы Мусага болай диде:
– Һарун угылларына – руханиларга – игълан ит: «Руха-
ни, үз халкы арасыннан үлгән кешенең мәетенә кагы-
лып, үзен пычратмаска тиеш. 2 Ул үзенең якын туганына, үзенең
анасы һәм атасына, үзенең угылы һәм кызына, үзенең ир туганына
3 һәм үзе белән яшәүче, әмма кияүгә чыкмаган кыз туганына гына
кагыла ала. 4 Ул хатыны ягыннан булган туганнары өчен үзен пыч-
ратырга тиеш түгел.

[5] Рухани үлгән кеше истәлегенә үзенең чәчен алырга, сакал
кырыйларын кыркырга һәм тәнендә тамга ясарга тиеш түгел.
[6] Ул үз Алласына изге булырга һәм Аллаһы исемен хурламаска
тиеш, чөнки ул Раббыга багышлап яндыру бүләген, ягъни Алла-
һының ризыкларын тәкъдим итә. Шулай булгач, ул изге булыр-
га тиеш.
[7] Рухани үзенә хатын итеп гыйффәтсез фахишә хатын-кызны,
шулай ук иреннән аерылган хатынны алмаска тиеш, чөнки рухани
үз Алласына изге. [8] Рухани изге дип исәпләнсен, чөнки ул Алла-
гызга ризык тәкъдим итә. Мин – Раббы, изге һәм сезне изге итү-
че. [9] Әгәр руханиның кызы, фәхешлек итеп, үзен нәҗесли икән, ул
үзенең атасын хур итә, һәм ул яндырып үтерелергә тиеш.
[10] Туганнары арасыннан сайланган, башына изгеләндерү мае
агызылган һәм руханилыкка багышланып, руханилык киемнәрен
кигән Баш рухани үлгән кеше истәлегенә чәчен тузгытмаска һәм
киемнәрен ертмаска тиеш. [11-12] Ул, үлгән кешенең мәете булган
йортка бару өчен, Изге чатырдан китәргә, чатырны нәҗесләргә
тиеш түгел; хәтта үлгән атасы һәм анасына кагылып та ул үзен
пычратырга тиеш түгел, чөнки ул, Алласының изгеләндерү мае бе-
лән майланып, Раббыга багышланган. Мин – Раббы. [13] Ул бары
тик гыйффәтле кызга гына өйләнергә тиеш. [14] Тол яки иреннән
аерылган яисә гыйффәтсез фахишә хатын-кызга өйләнергә тиеш
түгел; фәкать үз халкыннан булган гыйффәтле кызга гына өйлә-
нергә тиеш. [15] Шуңа күрә ул үз халкы арасында үзенең нәсел ва-
рисларын нәҗесләмәскә тиеш. Мин – Раббы, Баш руханины изге
итүче».
[16] Раббы Мусага болай диде:
[17] – Һарунга әйт: «Синең нәселеңнең киләчәк буыннарыннан
тәнендә кимчелек булган кеше, Алласына ризык тәкъдим итәргә
дип, Аның янына килмәскә тиеш. [18] Тәнендә кимчелек булган бер
генә кеше дә – сукыр да, аксак та, гарип тә, [19] аягы һәм кулы сын-
ган да, [20] бөкре, кәрлә, күзенә ак төшкән, кутырлы, корчаңгы, кү-
кәе бозылган да, [21] рухани Һарун нәсел варисларыннан тәнендә
җитешсезлек булган бер генә кеше дә, Раббыга багышлап яндыру
бүләге китерү өчен, Аның янына килергә тиеш түгел. Ул кимче-
лекле, шуңа күрә ул, үз Алласына ризык тәкъдим итәргә дип,
Аның янына килмәскә тиеш. [22] Андый кеше Аллаһының изге һәм
тулысынча изге ризыгын ашый алыр; [23] әмма ул чатыр эчендәге
пәрдә янына яки мәзбәхкә якынаерга тиеш түгел, чөнки аның
тәнендә кимчелек бар. Андый кеше Минем изге урынымны нә-
җесләргә тиеш түгел. Мин – Раббы, шуларны изге итүче».
[24] Муса боларны Һарунга, аның угылларына һәм барча исраил-
леләргә игълан итте.

*Изге ризык турындагы канун*

22 [1] Раббы, Мусага дәшеп, болай диде:
[2] – Һарунга һәм аның угылларына игълан ит: «Сез исраиллеләрнең Миңа багышлаган изге ризыклары белән сак эш итәргә һәм шул изге ризыклар аркылы Минем изге исемемне хур итмәскә тиеш. Мин – Раббы».

[3] – Аларга әйт: «Әгәр сезнең нәселегезнең киләчәк буыннарыннан берәү, үзендә нәҗеслек була торып, исраиллеләрнең Раббыга багышлаган изге ризыкларына якыная икән, ул кеше Минем күз алдымнан юк ителәчәк. Мин – Раббы.

[4-6] Һарун нәсел варисларыннан йогышлы тире авырулы яки бүлендекле кеше, нәҗеслегеннән арынганга кадәр, ул изге ризыкларны ашарга тиеш түгел. Рухани мәет яисә орлык аккан кеше нәҗесләгән әйбергә, берәр нәҗес сөйрәлүче хайванга яисә нинди дә булса нәҗес кешегә кагылса, ул кичкә кадәр нәҗес булыр; үзенең тәнен су белән юганчы, ул изге ризыкны ашарга тиеш түгел. [7] Ә
кояш батканнан соң ул чиста булыр; шул чакта ул китерелгән изге
ризыкны ашый алыр, чөнки бу – аның ризыгы. [8] Ул, нәҗесләнмәс
өчен, үзе үлгән яки ерткыч җанвар ботарлаган җәнлек итен ашарга тиеш түгел. Мин – Раббы.

[9] Руханилар Минем күрсәтмәләремне тотарга тиеш; югыйсә, күрсәтмәләремне хөрмәт итмәгән өчен, алар гаепле һәм һәлак булачак. Мин – Раббы, руханиларны изге итүче.

[10] Китерелгән изге ризыкны рухани гаиләсеннән тыш бер генә кеше дә ашарга тиеш түгел, хәтта руханиның кунагы да, руханиның ялчысы да изге ризыкны ашарга тиеш түгел. [11] Әгәр рухани
акчага кол сатып ала икән яки ул кол аның гаиләсендә туа икән,
ул кеше әлеге изге ризыкны ашый ала. [12] Әгәр руханиның кызы
рухани булмаган кешегә кияүгә чыга икән, ул кыз инде изге ризыкны ашарга тиеш түгел. [13] Ә инде руханиның кызы тол калса
яки иреннән аерылса, балалары булмаса, яшьлегендәге кебек, атасының өенә кире кайтса, ул кыз атасының ризыгын ашый ала; башка бер генә ят кеше дә аны ашарга тиеш түгел.

[14] Кем дә булса берәү, ниятләмичә, изге ризыкны ашый икән, ул кеше ашаган изге ризыкның бәясен руханига кайтарып бирергә һәм шуның биштән бер өлеше кадәр өстәп түләргә тиеш. [15-16] Ру-
ханилар исә ят кешегә изге ризыкларны ашарга рөхсәт итмәскә тиеш, һәм руханилар шуның белән исраиллеләрнең Раббыга бүләк иткән изге ризыкларын нәҗесләргә тиеш түгелләр; югыйсә, әлеге ят кеше гаепле булачак һәм җәзага тартылачак. Мин – Раббы, ул ризыкларны изге итүче».

*Корбан китерергә яраклы хайваннар*

17 Раббы Мусага болай диде:
18 – Һарунга, аның угылларына һәм барлык исраиллеләргә игъ-
лан ит: «Исраиллеләрнең яки алар арасында яшәүче читтән кил-
гәннәрнең берәрсе ант буенча яки ихтыяри рәвештә Раббыга тулаем
яндыру корбаны китерә икән, 19 Аллаһы корбанны кабул итсен
өчен, ул корбан эре терлек, сарык яисә кәҗәдән кимчелексез ата
хайван булырга тиеш. 20 Кимчелекле бернинди хайванны да ки-
термәгез, чөнки андый корбан Раббы тарафыннан кабул ителмәс.
21 Әгәр берәү, нәзерен үтәү өчен яки ихтыяри рәвештә, татулык кор-
баны итеп Раббыга эре яки вак терлек бүләк итә икән, ул корбан,
Аллаһыга мәгъкуль булсын өчен, кимчелексез булырга тиеш. 22 Су-
кыр, гарип, имгәнгән, җәрәхәтле, кутырлы яки корчаңгы хайванны
Раббыга китермәгез; һәм андый кимчелекле хайваннарны, Раббыга
багышлап яндыру бүләге итеп, мәзбәхкә салмагыз. 23 Нинди дә булса
гарип сыер яки сарыкны ихтыяри корбан итеп тәкъдим итәргә
мөмкин; әмма, нәзерне үтәү өчен, андый хайван корбанлыкка тәкъ-
дим ителсә, Раббы аны мәгъкуль күрмәячәк. 24 Күкәе сытылган,
бозылган, өзелгән яки киселгән хайванны Раббыга китермәгез һәм
үз җирегездә алай эшләмәгез. 25 Чит ил кешеләреннән алган шун-
дый кимчелекле хайваннарны үзегезнең Аллагызга ризык бүләге
итеп тәкъдим итмәгез; чөнки ул хайваннар имгәнгән, аларда ким-
челек бар; андый хайваннар Раббы тарафыннан кабул ителмәс».
26 Раббы Мусага болай диде:
27 – Бозау, бәрән яисә кәҗә бәтие туа икән, җиде көн анасы янында
булсын, ә сигезенче көннән башлап, ул Раббыга багышлап яндыру бү-
ләге өчен яраклы булыр. 28 Әмма сыерны бозавы белән яки сарыкны
бәрәне белән бер көнне чалмагыз. 29 Раббыга шөкер корбаны тәкъдим
итәсез икән, бу корбан Раббы тарафыннан кабул ителсен дип китере-
гез. 30 Андый корбанның ите шул ук көнне ашалып бетәргә тиеш; ул
корбанның итен иртә беләнгә кадәр калдырмагыз. Мин – Раббы.

31 – Минем боерыкларымны тотыгыз һәм үтәгез. Мин – Раббы.
32 Минем изге исемемне хур итмәгез; исраиллеләр Минем изге булу-
ымны танырга тиеш. Мин – Раббы, сезне изге итүче. 33 Сезнең Алла-
гыз булу өчен, Мин сезне Мисыр җиреннән алып чыктым. Мин –
Раббы.

*Шимбә көн*

**23** 1 Раббы Мусага болай диде:
2 – Исраиллеләргә Раббы билгеләгән бәйрәмнәр хакында
игълан ит: ул бәйрәмнәрдә изге җыелышлар үткәрелсен.
Мин билгеләгән бәйрәмнәр түбәндәгеләр: 3 «Алты көн эшләгез, ә

җиденче көнне – шимбә көн, ял көнендә, изге җыелыш үткәрегез; ул көнне бернинди эш тә эшләмәгез; бу, сез кайда гына яшәсәгез дә, Раббы хөрмәтенә ял көне».

*Коткарылу һәм Төче кумәч бәйрәме*

[4] «Билгеләнгән вакытларда үткәрелергә тиешле Раббы бәйрәмнәре – изге җыелышлар менә шулар: [5] беренче айның ундүртенче көнендә кояш батканда Раббы хөрмәтенә үткәрелә торган Коткарылу бәйрәме башлана; [6] шул ук айның унбишенче көнендә Раббы хөрмәтенә Төче кумәч бәйрәме башлана; җиде көн төче икмәк ашагыз. [7] Беренче көнне изге җыелыш үткәрегез; гадәттә эшли торган бер эшне дә эшләмәгез. [8] Җиде көн буе Раббыга багышлап яндыру бүләкләрен китерегез; җиденче көнне дә изге җыелыш үткәрегез; гадәттә эшли торган бер эшне дә эшләмәгез».

[9] Раббы Мусага болай диде:

[10] – Исраиллеләргә игълан ит: «Мин бирәчәк җиргә килгәч һәм анда уңыш җыеп алгач, уңышларыгызның беренче көлтәләрен руханига китерегез. [11] Рухани, бүләк Раббы тарафыннан кабул ителсен өчен, көлтәне Аның алдында селкетсен; аны рухани шимбә көннән соң икенче көнне селкетсен. [12] Көлтәне селкетү көнендә Раббыга тулаем яндыру корбаны итеп кимчелексез бер яшьлек тәкә бәрән китерегез. [13] Һәм бәрән белән бергә, Раббыга икмәк бүләге итеп, зәйтүн мае кушылган, бер епаның уннан ике өлеше кадәр иң яхшы бодай оны китерегез. Бу – Раббыга багышлап яндыру бүләге; ул хуш ис чыгарыр. Бу бүләк белән бергә һиннең* дүрттән бер өлеше кадәр шәраб бүләге дә китерегез. [14] Үзегезнең Аллагызга бүләккә тәкъдим иткән көнгә кадәр, әлеге уңышларыгыздан бернинди пешкән икмәк тә, кыздырылган һәм кыздырылмаган бөртек тә ашамагыз. Бу – сезнең киләчәк буыннарыгыз өчен кайда гына яшәсәләр дә үтәргә тиешле мәңгелек кагыйдә».

*Уңыш бәйрәме*

[15] «Көлтә китергән шимбәдән соң икенче көннән башлап, үзегезгә тулы җиде атна хисаплагыз; [16] җиденче атнадан соң, ягъни илленче көнне, Раббыга яңа бөртек бүләк итеп китерегез. [17] Үзегез яши торган һәр йорттан, беренче уңыш бүләге итеп, ике икмәкне селкетеп, Раббы алдына махсус бүләк итеп китерегез; ул икмәкләр бер епаның уннан ике өлеше кадәр иң яхшы бодай оныннан чүпрә белән пешерелгән булсын. [18] Икмәк белән бергә кимчелексез бер яшьлек җиде тәкә бәрән, бер үгез бозау һәм ике сарык тәкәсе тәкъдим итегез; алар Раббыга тулаем яндыру корбаны булыр. Шул корбаннар, икмәк һәм шәраб бүләкләре белән бергә – яндыру

---

* 23:13 *Һин* – 6 литр чамасы.

бүләге; ул Раббы алдында хуш ис чыгарыр. [19] Шулай ук, гөнаһ йолу
корбаны итеп, бер кәҗә тәкәсе һәм, татулык корбаны итеп, берәр
яшьлек ике тәкә бәрән китерегез. [20] Рухани беренче уңыш икмәге
һәм ике бәрән белән бергә, махсус бүләк итеп, аларны Раббы ал-
дында селкетсен. Бу – Раббыга изге бүләк, ул руханиныкы. [21] Шул
ук көнне изге җыелыш үткәрегез; ул көнне гадәттә эшли торган
бер эшне дә эшләмәгез. Бу – сезнең киләчәк буыннарыгыз өчен
кайда гына яшәсәләр дә үтәргә тиешле мәңгелек кагыйдә.

[22] Иген кырыгызның уңышын җыйган вакытта читенә кадәр җит-
кереп урмагыз һәм урганнан калган башакларны кабат җыймагыз;
аларны фәкыйрьләргә һәм читтән килеп урнашканнарга калдыры-
гыз. Мин – Раббы Аллагыз».

*Быргылар бәйрәме*

[23] Раббы Мусага болай диде:

[24] – Исраиллеләргә игълан ит: «Җиденче айның беренче көне –
сезнең өчен махсус ял көне; ул көнне, быргылар кычкырткач, изге
җыелыш үткәрегез. [25] Ул көнне гадәттә эшли торган бер эшне дә
эшләмәгез һәм Раббыга багышлап яндыру бүләге китерегез».

*Гөнаһ йолу көне*

[26] Раббы Мусага болай диде:

[27] – Җиденче айның унынчы көнендә, Гөнаһ йолу көнендә, изге
җыелыш үткәрегез; бу көнне ураза тотыгыз һәм Раббыга багышлап
яндыру бүләге китерегез. [28] Ул көнне бернинди дә эш эшләмәгез;
чөнки ул – Гөнаһ йолу көне, Раббы Аллагыз алдында сезне гөнаһ-
лардан арындыру көне. [29] Ә инде ул көнне ураза тотмаган кеше үз
халкыннан читләштерелергә тиеш. [30] Әгәр кем дә булса берәү ул
көнне нинди дә булса эш эшләсә, андый кешене Мин үз халкы ара-
сыннан юк итәчәкмен. [31] Ул көнне бернинди дә эш эшләмәгез. Бу –
сезнең киләчәк буыннарыгыз өчен кайда гына яшәсәләр дә үтәргә
тиешле мәңгелек кагыйдә. [32] Бу – сезнең өчен махсус ял көне, сез
ураза тотарга тиеш. Бу айның тугызынчы көне киченнән башлап
иртәгесе көннең кичենә кадәр шимбә көнне тотыгыз.

*Чатырлар бәйрәме**

[33] Раббы Мусага әйтте:

[34] – Исраиллеләргә игълан ит: «Җиденче айның унбишенче көнен-
нән башлап җиде көн буе Раббыга багышланган Чатырлар бәйрәме
уздырылсын. [35] Беренче көнне изге җыелыш үткәрегез, гадәттә эшли
торган бер эшне дә эшләмәгез. [36] Җиде көн буе Раббыга багышлап

* *Чатырлар бәйрәме* – Бөртекле ашлык җыю бәйрәменең икенче исеме (карагыз: «Чыгыш» китабы 23:16).

яндыру бүләге китерегез; сигезенче көнне тагын изге җыелыш үткәрегез һәм янә Раббыга багышлап яндыру бүләге китерегез; бу – изге бәйрәм, ул көнне гадәттә эшли торган бер эшне дә эшләмәгез.

(37 Раббының бәйрәмнәре менә шулар: андый көннәрдә изге җыелыш үткәрелергә тиеш; ул бәйрәмнәрдә, һәрберсенең үз көнендә, Раббыга багышлап яндыру бүләкләре – тулаем яндыру корбаннары, икмәк бүләкләре, башка корбаннар һәм шәраб бүләкләре китерегез. 38 Бу бәйрәмнәрне Раббының шимбә көннәреннән тыш үткәрегез. Бу көннәрдә нәзер буенча да, ихтыяри рәвештә дә, гадәти бирелә торган бүләкләр белән беррәттән, Раббыга өстәмә бүләкләр дә тәкъдим итегез.)

39 Җиденче айның унбишенче көненнән башлап, җирегезнең уңышын җыеп алгач, җиде көн буена Раббы хөрмәтенә бәйрәм итегез; беренче һәм сигезенче көн махсус ял көннәре булсын.
40 Бәйрәмнең беренче көнендә агачларның иң яхшы җимешләрен, хөрмә агачының һәм зур яфраклы агачларның ботакларын, шулай ук елга ярында үскән куакларның ботакларын сындырып алыгыз һәм Раббы Аллагыз алдында җиде көн күңел ачыгыз. 41 Шул көннәрне ел саен җиде көн буе Раббы хөрмәтенә бәйрәм итегез. Бу – сезнең киләчәк буыннарыгыз өчен мәңгелек кагыйдә. Аны җиденче айда бәйрәм итегез. 42 Җиде көн буена чатырда яшәгез; барлык җирле исраиллеләр җиде көн дәвамында чатырда яшәсен; 43 шуңа күрә сезнең нәсел варисларыгыз белерләр: Мин, исраиллеләрне Мисыр җиреннән алып чыкканда, аларны чатырларга урнаштырган идем. Мин – Раббы Аллагыз».

44 Муса Раббы билгеләгән бәйрәмнәр хакында исраиллеләргә игълан итте.

*Изге булмәдәге яктырткыч һәм икмәк турындагы кагыйдә*

**24** 1 Раббы Мусага болай диде:
2 – Исраиллеләргә, яктырткычлар һәрвакыт янып торсын өчен, үзенә иң яхшы чиста зәйтүн мае китерелсен дип әмер ит. 3 Изге чатырда, боерыклар сандыгы алдындагы пәрдә тышында, Раббы алдындагы яктырткычларда ут кичтән алып иртәнгә кадәр янсын өчен, Һарун яктырткычларны һәрвакыт карап торсын. Бу – сезнең киләчәк буыннарыгыз өчен мәңгелек кагыйдә. 4 Раббы алдындагы саф алтын шәмдәлгә куелган яктырткычларда ут һәрвакыт янып торырга тиеш.

5 Иң яхшы бодай оны ал да аннан унике икмәк пешер; һәр икмәктә бер епаның уннан ике өлеше кадәр он булсын. 6 Аларны Раббы алдындагы саф алтын белән каплатылган өстәл өстенә алтышардан ике рәт итеп тезеп куй. 7 Һәр рәт өстенә хуш исле саф сумала куй; сумала, барлык бүләкнең бер өлеше буларак, икмәкне алмаштыру өчен, Раббыга багышлап яндыру бүләге булсын. 8 Һәр шимбә көнне

бу икмәкләр Раббы алдына куелырга тиеш; бу – исраиллеләрнең мәңгелек вазифасы.
[9] Ул икмәкләр Һарун белән аның угылларына була, һәм алар аны изге урында ашасыннар, чөнки бу – мәңгегә аларныкы, Раббыга багышлап яндыру бүләкләренең тулысынча изге өлеше.

*Раббыны хурлаган кеше турындагы канун*

[10] Шулвакыт исраилле бер хатынның мисырлыдан туган угылы исраиллеләр арасына чыкты да тукталу урынында яшәүче бер исраилле белән ызгыш башлады.
[11] Исраилле хатынның угылы, Раббы исемен хурлап, яман сүзләр әйтте. Шуңа күрә аны Муса янына алып килделәр. (Бу егетнең анасы Дан ыругыннан Дибри кызы Шеломит иде.)
[12] Раббының ихтыяры игълан ителгәнгә кадәр, аны сак астына алдылар.

[13] Шуннан соң Раббы Мусага болай диде:

[14] – Яман теллеләнгән кешене тукталу урыныннан читкә чыгар, аның хурлавын ишеткән кешеләр кулларын шул кешенең башына куйсыннар, һәм барча халык аны ташлар белән бәргәләсен.
[15] Исраиллеләргә игълан ит: «Кем дә булса үзенең Алласын хурлый икән, ул җәзага тартылырга тиеш.
[16] Раббының исемен хурлаучы үлемгә тапшырылырга һәм аны барча халык ташлар белән бәргәләргә тиеш. Читтән килгән кешеме ул, җирле кешеме, әгәр Раббы исемен хурлый икән, шундук үлемгә тапшырылырга тиеш.

[17] Әгәр берәр кеше нинди дә булса кешене үтерә икән, ул үлемгә тапшырылырга тиеш.
[18] Кем дә булса берәү икенче бер кешенең хайванын үтерә икән, аның өчен хайван бирергә тиеш. Кагыйдә шундый: жанга жан түләнергә тиеш.
[19] Кем дә булса берәү иптәшенең тәненә зыян ясый икән, ул нинди зыян китергән булса, үзенә дә шундый ук зыян китерелергә тиеш.
[20] Имгәткән өчен – имгәтү, күз өчен – күз, теш өчен теш булсын; ул башка кешенең тәненә ничек зыян китергән булса, аңа да шулай эшләнсен.
[21] Кем дә булса хайван үтерә икән, шуның өчен хайван белән түләргә тиеш; ә инде кеше үтерсә, үзе дә үлемгә тапшырылырга тиеш.
[22] Читтән килгән кеше өчен дә, җирле кеше өчен дә сездә канун бер булсын. Мин – Раббы Аллагыз».

[23] Шуннан соң Муса моны исраиллеләргә игълан итте. Алар яман теллеләнгән кешене тукталу урыныннан читкә чыгардылар һәм аны ташлар белән бәргәләделәр. Раббы Мусага ничек әмер иткән булса, исраиллеләр шулай эшләде.

*Җиденче ел – җир ял итә торган ел*

**25**

[1] Синай тавында Раббы Мусага болай диде:
[2] – Исраиллеләргә сөйлә һәм игълан ит: «Мин сезгә бирәчәк җиргә килгәч, сез, Раббыга хөрмәт йөзеннән, һәр җиденче елны җиргә ял бирергә тиеш.
[3] Алты ел кырыгызга ашлык чәчегез; алты ел йөзем бакчагызны үстерегез һәм уңышларыгызны

җыеп алыгыз. 4 Ә Җиденче ел – җир өчен махсус ял елы: ул – Раббы
хөрмәтенә ял елы. Кырларыгызга ашлык чәчмәгез, йөзем куакла-
рыгызны кыркымагыз. 5 Үзе үскән ашлыгыгызны урмагыз, үзегез
карамаган йөзем агачларыгызның җимешләрен җыймагыз; бу ел җир
өчен махсус ял елы булсын. 6-7 Ял елында җир сезнең һәммәгезне:
үзегезне һәм колларыгызны да, җарияләрегезне, ялчыларыгызны,
арагызда вакытлыча яшәүчеләрне, хайваннарыгызны, җирегездә
яшәгән ерткыч җәнлекләрне дә ризык белән тәэмин итәр. Җирдә-
ге үзе тишелеп чыгып үскән бөтен ашлык сезгә ризык булыр».

*Илленче ел – коллар һәм мирас мөлкәте кайтару елы*

8 «Җиде мәртәбә җидешәр Җиденче елны исәпләп чыгарыгыз –
барлыгы кырык тугыз ел булсын. 9 Ә җиденче айда, айның унынчы
көнендә, ягъни Гөнаһ йолу көнендә, һәр урында быргылар кыч-
кыртыгыз. 10 Илленче елны изгеләндерегез, җирдә яшәүче барлык
кешеләргә азатлык игълан итегез; һәркем үз гаиләсенең биләмәсе-
нә кайтсын, һәркем үз кабиләсенә кушылсын. 11 Илленче елда аш-
лык чәчмәгез, үзе үскән ашлыгыгызны урмагыз, үзегез карамаган
йөзем агачларыгызның җимешләрен җыймагыз, 12 чөнки бу – Ил-
ленче, сезнең өчен изге ел. Җирдә үзе үскән нәрсәне генә ашагыз.
13 Илленче елда һәркем үз гаиләсенең биләмәсенә кайтсын. 14 Әгәр
берәр иптәшегезгә җир сатсагыз яки аннан җир сатып алсагыз,
бер-берегезне алдамагыз. 15 Җирне сатканда, аның бәясен киләчәк
Илленче елга кадәр калган уңыш елларының санын кертеп исәп-
ләгез. 16 Еллар саны күп булса, бәяне күтәрегез, ә инде еллар саны
аз булса, бәясен киметегез, чөнки бары тик җыеп алган уңыш ел-
ларының саны гына сатыла. 17 Бер-берегезне алдамагыз, үзегезнең
Аллагыздан куркып, Аны хөрмәт итегез. Мин – Раббы Аллагыз.
18 Минем кагыйдәләремне һәм кануннарымны саклап, шулар бе-
лән гамәл кылыгыз; шулай эшләсәгез, җир йөзендә имин яшәр-
сез. 19 Менә шул чагында җир үзенең җимешләрен бирер һәм сез
туйганчы ашарсыз вә анда имин яшәрсез.
20 „Ашлыкны чәчмәгәч тә, урып та җыймагач, Җиденче елда без
нәрсә ашарбыз соң?“ – диярсез.
21 Мин алтынчы елга Үземнең фатихамны җибәрермен, һәм җир
сезгә өч елга җитәрлек уңыш бирер. 22 Сигезенче елда иген иккән-
дә дә, тугызынчы елда уңыш өлгергәнгә кадәр, әле һаман искедән
калган икмәкне ашарсыз.
23 Җир гомерлеккә сатылырга тиеш түгел, чөнки җир – Минеке;
сез исә бу җирдә читтән килгәннәр һәм вакытлыча яшәүчеләр ке-
бек кенә. 24 Биләмәгездәге һәр урынны йолым түләп алырга рөхсәт
ителергә тиеш.
25 Әгәр берәр туганың, бөлгенлеккә төшеп, үзенең биләмәсен
сата икән, аның иң якын кардәше ул саткан җирне йолым түләп

алсын. [26-27] Әгәр аның өчен йолым түләүче булмаса һәм соңрак
үзе баеп китеп, йолым түләп алырга мөмкинлек тапса, ул, саткан-
нан соңгы елларны исәпләп һәм киләчәк Илленче елга кадәр кал-
ганнарын сатып алган кешегә кире кайтарып биреп, үз биләмәсенә
яңадан хуҗа булсын. [28] Әгәр ул, саткан җирен кире алу өчен, сатып
алучыга түләрлек йолым таба алмаса, саткан җире киләчәк Иллен-
че елга кадәр сатып алган кеше кулында калсын, ә инде Илленче
елда аның кулыннан китсен, һәм саткан кеше яңадан милек иясе
булсын.

[29] Әгәр берәү диварлы шәһәрдәге үз йортын сата икән, сатканнан
соң бер ел үткәнгә кадәр, аны йолым түләп кире алырга мөмкин;
беренче ел эчендә аны кире сатып алырга мөмкин. [30] Әгәр тулы
бер ел эчендә йолым түләп йортын кире ала алмаса, ул йорт сатып
алган кешенең һәм аның нәсел варисларының кулында гомергә кал-
сын, киләчәк Илленче елда да аның кулыннан китмәсен. [31] Әйлә-
нә-тирәсендә дивары булмаган авыл йортлары кыр җире кебек са-
налсын; аларны йолым түләп алырга мөмкин һәм киләчәк Илленче
елда алар сатып алучының кулыннан китсен.

[32] Левиләргә билгеләнгән шәһәрләрдә үз йортларын алар һәрва-
кыт йолым түләп ала алалар. [33] Левиләр үз биләмәләрен йолым тү-
ләп алырга мөмкин. Левиләргә билгеләнгән шәһәрләрдә алар үзлә-
ре саткан йортлар киләчәк Илленче елда хуҗасына кире кайтарып
бирелсен, чөнки левиләрнең үз шәһәрләрендәге йортлары исраил-
леләр арасында аларның биләмәсе булып исәпләнә. [34] Әмма алар-
ның шәһәр тирәсендәге кырларын сатарга ярамый, чөнки ул кыр-
лар – аларның мәңгелек биләмәсе.

[35] Берәр туганыгыз ярлыланса һәм үз-үзен тәэмин итәрлек хәле
калмаса, аңа, читтән килгән кешегә яки вакытлыча яшәүчегә яр-
дәм иткән кебек, ярдәм итегез; ул сезнең арагызда яшәвен дәвам
итәрлек булыр. [36] Әҗәткә бирелгән акча өчен аңардан бернинди
өстәмә алмагыз; үзегезнең Аллагыздан куркып, Аны хөрмәт ите-
гез; менә шулай сезнең туганыгыз сезнең арагызда яшәсен. [37] Аңа
әҗәткә биреп торган акчагыздан да, саткан азык-төлегегездән дә
риба* алмагыз. [38] Кәнган җирен сезгә бирү һәм сезнең Аллагыз булу
өчен, Мин – Раббы Аллагыз, сезне Мисыр җиреннән алып чыктым.

[39] Әгәр берәр туганың фәкыйрьлеккә төшеп, үзен сиңа сатса,
син аны кол кебек эшләтмә. [40] Ул ялчы кебек яки синең яныңда
вакытлыча яшәүче кебек булырга тиеш; ул киләчәк Илленче елга
кадәр сиңа эшләсен. [41] Шуннан соң ул үзе дә, аның балалары да
синең яннан китсеннәр; ул үзенең кабиләсенә һәм ата-бабалары-
ның биләмәсенә кайтсын. [42] Чөнки исраиллеләр – Минем колла-
рым, аларны Мин Мисыр җиреннән алып чыктым, шуңа күрә алар

* 25:37 *Риба* – биреп торган әйбер йә акчадан алынган процент.

колларны саткан кебек сатылырга тиеш түгелләр. 43 Алар өстеннән
рәхимсез хакимлек итмәгез, Аллагыздан куркып, Аны хөрмәт итегез.
44 Сезнең ир-ат яисә хатын-кыз колларыгыз әйләнә-тирәгездәге
башка халыклардан булсын. Алардан үзегезгә кол сатып ала ала-
сыз. 45 Шулай ук сезнең арагызда вакытлыча яшәүчеләрдән һәм
шул гаиләләрнең сезнең җирегездә туган балаларыннан үзегезгә кол
сатып алырга мөмкин, һәм алар сезнең милкегез булыр. 46 Аларны
мирас милке итеп балаларыгызга калдыра аласыз; ул коллар го-
мерлеккә сезнеке була ала. Ә үзегезнең туганнарыгыз, исраилле-
ләр өстеннән шәфкатьсез хакимлек итәргә тиеш түгелсез.
47 Әгәр читтән килгән һәм сезнең арагызда яшәүче яки вакыт-
лыча яшәүче берәр кеше баеса, ә сезнең берәр туганыгыз бөлген-
леккә төшеп, әлеге читтән килеп урнашкан кешегә яки аның гаи-
ләсеннән булган берәүгә сатылса, 48 ул йолым түләп алына ала; аны
берәр туганы йолым түләп алырга мөмкин. 49 Абыйсы, абыйсының
угылы яки аның кабиләсеннән кем дә булса берәү аны йолым тү-
ләп алсын. Әгәр хәлләнеп китсә, ул үзен үзе йолым түләп ала ала.
50 Ул үзен сатып алган кеше белән үзе сатылган елдан башлап ки-
ләчәк Илленче елга кадәр калган елларны санап исәпләшсен.
Аның үзен азат итү бәясе шул елларның санына карап билгелән-
сен, һәм ул бәя ялчы хакы кебек исәпләнсен. 51 Әгәр калган еллар
саны күп булса, ул, әлеге еллар санына карап, күбрәк йолым тү-
ләргә тиеш. 52 Киләчәк Илленче елга кадәр калган еллар саны аз
булса, шул еллар санына карап, ул үзе өчен азрак йолым түләсен.
53 Ул барлык елларга ялчы булып калсын. Күзәтегез, хуҗасы аның
белан идарә иткәндә рәхимсез булмасын. 54 Әгәр шул рәвешле йо-
лым түләп алынмаса, ул үзе һәм аның балалары киләчәк Илленче
елда азат ителергә тиеш. 55 Чөнки исраиллеләр – Минем колла-
рым; Мисыр җиреннән Мин аларны Үзем алып чыктым. Мин –
Раббы Аллагыз».

*Итагатьлелек өчен фатиха*

**26** 1 «Үзегезгә потлар ясамагыз, сыннар яки табына торган
таш баганалар утыртмагыз, җирегездә табыну өчен сыр-
лы ташлар куймагыз. Мин – Раббы Аллагыз. 2 Минем
шимбә көннәремне тотыгыз һәм Минем изге урынымны хөрмәт
итегез. Мин – Раббы.
3 Әгәр Минем кагыйдәләрем буенча яшәсәгез, Минем боерык-
ларымны сакласагыз һәм үтәсәгез, 4 Мин сезгә вакытында яңгыр
яудырырмын; шунлыктан җир үзенең уңышын вә агачлар үзләре-
нең җимешләрен бирер. 5 Сезнең уңышыгыз шулчаклы мул булыр
ки, ашлык сугу вакытыгыз йөзем җыйган вакытка кадәр, ә йөзем
җыю ашлык чәчү вакытына кадәр дәвам итәр; һәм сез икмәкне
туйганчы ашарсыз, үз җирегездә имин яшәрсез.

[6]Җирегезгә тынычлык җибәрермен. Йокыга яткан вакытыгызда
сезне һичкем куркытмас. Җирегездән ерткыч җәнлекләрне куар-
мын һәм җирегезгә һичкем һөҗүм итмәс. [7]Сез дошманнарыгызны
куып җибәрерсез. Сугышканда алар сезнең алдыгызда җиңелер-
ләр. [8]Сезнең бишегез – йөз дошманны, ә йөзегез ун мең дошман-
ны куар, сугышканда дошманнарыгыз сезнең алдыгызда кылычтан
кырылыр.

[9]Сезнең хакта кайгыртырмын, үрчемле итәрмен һәм ишәйтер-
мен, сезнең белән төзегән килешүемне тотармын. [10]Иген уңышы-
гыз шулчаклы мул булыр ки, сез узган елгы икмәкне ашарсыз һәм,
яңасына урын әзерләү өчен, искесен чыгарып ташларсыз. [11]Ә Мин
Үз торагымны сезнең арага куярмын, һәм Минем җаным сезне
нәфрәт итмәс. [12]Мин сезнең арагызда йөрермен, сезнең Аллагыз
булырмын, ә сез Минем халкым булырсыз. [13]Мин – Раббы Алла-
гыз, сезне, кол булмасыннар дип, Мисырдан алып чыктым. Мин
сезнең богауларыгызны өзеп ташладым һәм сезне иректе вә горур
хәлдә алып бардым».

*Итагатьсезлек өчен җәза*

[14]«Әгәр Мин әйткәннәрне тыңламасагыз, барлык шушы боерык-
ларымны үтәмәсәгез, [15]кагыйдәләремне кире каксагыз, канунна-
рымны нәфрәт итсәгез, барлык боерыкларымны үтәмәсәгез һәм
шул рәвешле килешүемне бозсагыз, [16]Мин дә сезнең белән шулай
эш итәрмен: сезгә дәһшәт, төрле авырулар һәм бизгәк җибәрермен.
Күзләрегез күрмәс булыр, һәм шул авырулар гомерегезне алып ки-
тәр. Ашлык чәчәрсез, әмма чәчкән игенегезнең бәрәкәтен күр-
мәссез, чөнки уңышыгызны дошманнарыгыз ашар. [17]Мин сезгә
каршы чыгармын; шуңа күрә дошманнарыгыз алдында җиңелер-
сез, өстегездән дошманнарыгыз хакимлек итәр, һәм сез шулкадәр
куркак булырсыз ки, эзәрлекләүче булмаганда да качарсыз.

[18]Әгәр дә сез, шуларга да карамастан, Мине тагын да тыңлама-
сагыз, гөнаһларыгыз өчен җәзамны җиде мәртәбә арттырырмын.
[19]Сезнең тәкәбберлегегезне сындырырмын, күгегезне тимер күк,
җирегезне бакыр күк итәрмен. [20]Сез көчегезне юкка гына сарыф
итәрсез, чөнки җирегез уңыш китермәс һәм җирегездәге агачлар
җимеш бирмәс.

[21]Әгәр шуннан соң да киреләнеп Мине тыңларга теләмәсәгез,
гөнаһларыгыз өчен җәзамны янә дә җиде мәртәбә арттырырмын.
[22]Сезгә каршы ерткыч җәнлекләр җибәрермен; алар балаларыгыз-
ны үтерерләр һәм терлекләрегезне юкка чыгарырлар, нәтиҗәдә,
сезнең саныгыз бик нык кимер, юлларыгыз бушап калыр.

[23-24]Инде болардан соң да шелтәмне кабул итмәсәгез һәм Миңа
каршы тагын да киреләнсәгез, Мин дә сезгә каршы чыгармын
һәм гөнаһларыгыз өчен җәзамны җиде мәртәбә арттырырмын. [25]Ә

килешүне бозган өчен, сездән үч алып, сугыш китерермен; үзегез-
не саклау өчен сез шәһәрләрегезгә кереп туплансагыз да, Мин
сезгә каршы үләт җибәрермен, һәм сез дошманнарыгыз кулына
бирелерсез. [26] Мин сезнең икмәгегезне бетерермен; шунлыктан ун
хатын бер мичтә икмәк пешерер, һәм ул үлчәп кенә бирелер; сез
ашарсыз, әмма туймассыз.

[27-28] Әгәр дә инде болардан соң да Мине тыңламасагыз һәм Ми-
ңа каршы киреләнсәгез, Мин ачуым белән сезгә каршы барырмын
һәм гөнаһларыгыз өчен җиде мәртәбә артыграк җәза бирермен.
[29] Үз угылларыгызның һәм кызларыгызның итен ашарсыз. [30] Биек-
лектәге сынга табына торган урыннарыгызны туздырырмын, хуш
исле сумала яндыру урыннарыгызны җимерермен, мәетләрегезне
потларыгызның ватыклары өстенә өярмен, һәм Минем җаным
сезне нәфрәт итәр. [31] Шәһәрләрегезне бушлыкка әверелдерермен,
изге урыннарыгызны җимерермен һәм бүләкләрегезнең хуш исе
белән рәхәтләнмәм. [32] Җирегезне бөлгенлеккә төшерермен, хәтта
аны басып алучы дошманнарыгыз да хәйран калыр. [33] Үзегезне
башка халыклар арасына таратырмын һәм сезгә сугыш җибәрер-
мен, җирегез буш булыр, шәһәрләрегез җимерелер. [34] Сез дошман-
нарыгыз җирендә булган вакытта, җирегез ташландык хәлдә бул-
ган көннәрдә, ул җир үзенең ял көннәре белән канәгать булыр,
менә шул чакта җир тыныч ятар һәм үзенең ял көннәре өчен үзен
канәгатьләндерер. [35] Җир үзенең ташландык көннәрендә, сез анда
яшәгән чакта, ял көннәрендә күрмәгән рәхәтлекне кичерер.

[36] Дошманнарыгыз җирендә калганнарыгызның йөрәкләрендә
курку тудырырмын һәм алар, яфрак селкенгән тавыштан да куркып,
сугыштан качкан кебек качарлар һәм, һичкем эзәрлекләмәгәндә
дә, куркып егылырлар. [37] Һичкем эзәрлекләмәгән хәлдә дә, сугыш-
тан куркып качкан кебек, алар бер-берсенә абынып егылырлар һәм
дошманнарына каршы торырлык хәлләре булмас. [38] Сез чит халык-
лар арасында һәлак булырсыз, һәм дошманнарыгызның җире сезне
йотар. [39] Ә инде исән калучылар булса, алар, үзләренең һәм ата-ба-
баларының гөнаһлары өчен, дошман җирендә хәлсезләнерләр.

[40] Әгәр алар үзләренең һәм ата-бабаларының гөнаһларын, Миңа
каршы җинаять эшләүләрен һәм Миңа каршы киреләнүләрен та-
нып сөйләсәләр [41] һәм шуның өчен Минем аларга каршы чыгуым-
ны һәм аларны дошман җиренә сөрүемне аңласалар, шул чагында,
имансыз йөрәкләре күндәм булса, алар үзләренең гөнаһлары өчен
җәза алсалар, [42] Мин Ягъкуб, Исхак һәм Ибраһим белән төзегән ки-
лешүемне искә төшерермен, шулай ук җирне дә искә төшерермен.
[43] Ул җир, алардан бушап калганнан соң, үзенең ял көннәреннән
канәгатьләнер; ә алар үзләренең гөнаһлары өчен җәза алырлар,
чөнки алар Минем кануннарымны кире кагып, җаннары Минем
кагыйдәләремнән нәфрәтләнде. [44] Шулай булса да, алар дошман

җирендә чакта да, аларны тулысынча юк итмәс һәм алар белән төзегән килешүемне бозмас өчен, аларны бөтенләй кире какмам һәм нәфрәтләнмәм. Мин – Раббы, аларның Алласы. [45] Мин алар өчен аларның ата-бабалары белән төзегән килешүемне исемә төшерермен. Мин, аларның Алласы булу өчен, халыкларның күз алдында, аларның ата-бабаларын Мисыр җиреннән алып чыктым. Мин – Раббы».

[46] Синай тавында Муса аша Раббының исраиллеләр белән төзегән кагыйдә, карар һәм кануннары менә шулар.

*Аллаһыга бүләкләр багышлау турындагы канун*

# 27

[1] Раббы Мусага болай диде:
[2] – Исраиллеләргә игълан ит: «Әгәр кем дә булса берәү җанын Раббыга багышларга махсус нәзер иткән булса, ул җан өчен билгеләнгән бәя Раббыга багышлансын. [3] Билгеләнгән бәя егерме яшьтән алтмыш яшькә кадәрге ир-ат өчен рәсми үлчәм буенча илле шәкыл* көмеш булсын. [4] Әгәр ул хатын-кыз булса, билгеләнгән бәя утыз шәкыл көмеш булсын. [5] Биш яшьтән егерме яшькә кадәр булганнарга билгеләнгән бәя – ир-ат өчен егерме шәкыл көмеш, ә хатын-кыз өчен ун шәкыл көмеш булсын.
[6] Ә инде бер айлыктан биш яшькә кадәр булганнарга билгеләнгән бәя – ир-ат өчен биш шәкыл көмеш, ә хатын-кыз өчен өч шәкыл көмеш булсын. [7] Алтмыш яшьлекләр һәм өлкәнрәкләр өчен билгеләнгән бәя – ир-ат өчен унбиш шәкыл көмеш, ә хатын-кыз өчен ун шәкыл көмеш булсын. [8] Әгәр ул нәзер иткән кеше фәкыйрь булса һәм билгеләнгән бәяне түләрлек хәле булмаса, багышланган кешене рухани алдына китерсеннәр, һәм рухани, нәзер әйтүченең хәленә карап, аның бәясен билгеләсен.

[9] Әгәр нәзер Раббыга корбан китерергә яраклы хайван булса, Раббыга биргелгән һәр нәрсә Аныкы була. [10] Нәзер итеп хайван биргән кеше аны башка хайван белән – яхшыны начарга яки начарны яхшыга алмаштырырга тиеш түгел; әгәр дә берәү бер хайванны икенче хайван белән алмаштыра икән, тегесе дә, монысы да Раббыныкы була. [11] Әгәр ул хайван нәҗес булып, Раббыга корбан китерергә ярамый торган булса, теге кеше андый хайванны рухани алдына китерергә тиеш. [12] Рухани, ул хайванның яхшы яки начар сыйфатын исәпләп, аның бәясен билгеләсен; рухани ничек билгеләсә, бәя шундый булыр. [13] Әгәр ул кеше аны йолым түләп алырга теләсә, ул билгеләнгән бәянең биштән бер өлеше кадәр өстәп бирергә тиеш.

[14] Әгәр берәү, үзенең йорты Раббыныкы булсын өчен, аны Раббыга багышлый икән, рухани, ул йортның яхшы яки начар сыйфатын

---

* 27:3 *Шәкыл* – 10 грамм чамасы.

исәпләп, аның бәясен билгеләсен; рухани ничек билгеләсә, бәя
шундый булыр. [15] Әгәр багышлаган кеше үзенең йортын йолым тү-
ләп кире алырга тели икән, билгеләнгән бәянең биштән бер өле-
ше кадәр өстәп түләргә тиеш; шуннан соң йорт янә аныкы булыр.

[16] Кем дә булса берәү үзенең ата-бабасыннан мирас булып күч-
кән кырның бер өлешен Раббыга багышласа, билгеләнгән бәя шул
җиргә чәчә торган кирәкле орлык күләменчә, бер хомер* арпа ор-
лыгы өчен илле шәкыл көмеш булсын. [17] Әгәр дә берәү үзенең
кырын Илленче елдан башлап багышлый икән, аның бәясе бил-
геләнгән тулы күләмдә булсын. [18] Кем дә булса үзенең кырын Ил-
ленче елдан соң багышлый икән, рухани киләчәк Илленче елга
кадәр калган елларның санына карата аның бәясен хисаплап чыгар-
сын һәм билгеләнгән бәяне киметсен. [19] Әгәр багышлаучы үзе-
нең җирен йолым түләп алырга тели икән, билгеләнгән бәянең
биштән бер өлеше кадәр өстәп түләргә тиеш; шуннан соң кыр янә
аныкы булыр. [20] Әгәр ул кырны йолым түләп алмаса һәм ул кыр
башка бер кешегә сатылса, аны йолым түләп кире ала алмас. [21] Ул
кыр, киләчәк Илленче елда кире алынмыйча, мәңге багышлан-
ган кыр буларак, Раббыныкы булыр һәм ул руханиларның мөлкә-
тенә әверелер.

[22-23] Әгәр дә берәү үзенең сатып алган кырын, ата-бабасыннан
мирас булмаган мөлкәтен, Раббыга багышлый икән, рухани аңа
киләчәк Илленче елга кадәр калган елларның санынча җирнең бә-
ясен хисапласын, ул кеше билгеләнгән бәяне шул ук көнне бирер-
гә тиеш. Бу бәя Раббыныкы булыр. [24] Ул кыр кемнән сатып алын-
ган булса, киләчәк Илленче елда аңа – кыр саткан кешегә, бе-
ренче милек иясе булган кешегә – кире кайтарып бирелсен. [25] Һәр
билгеләнгән бәя рәсми үлчәм буенча бәяләнергә тиеш: егерме
гера* – бер шәкыл.

[26] Хайваннарның беренче булып туганнары Раббыныкы, шуңа
күрә беркем дә аны багышларга тиеш түгел; эре терлекме ул яки
вак терлекме – барысы да Раббыныкы. [27] Әгәр ул нәҗес хайван
булса, аны, билгеләнгән бәянең биштән бер өлеше кадәр өстәп, йо-
лым түләп алырга мөмкин. Әгәр йолым түләп алынмаса, хайван
билгеләнгән бәядән сатылсын.

[28] Әмма Раббыга мәңге багышланып нәзер ителгән бер генә нәр-
сә дә – кешеме, хайванмы яки ата-бабасыннан мирас булып кал-
ган мөлкәтме – берсе дә сатыла һәм йолым түләп кире алына ал-
мый. Шул рәвешле, багышланган һәр нәзер тулысынча Раббыны-
кы булыр. [29] Мәңгегә багышланып нәзер ителгән бер генә кеше дә
йолым түләп кире алына алмый, ул үлемгә тапшырылырга тиеш.

---

* 27:16 *Хомер* – 100-200 литр чамасы.
* 27:25 *Гера* – 0,5 грамм чамасы.

[30] Җирдән алынган барлык уңышның һәм агачлардан җыеп алын-
ган җимешнең уннан бере – Раббыныкы. Ул гошер* – Раббы өчен
изге. [31] Әгәр кем дә булса берәү әлеге өлешне йолым түләп алырга
тели икән, ул кеше аның бәясенә биштән бер өлеше кадәр өстәп
бирергә тиеш. [32] Барлык эре һәм вак терлекләр, көтүче таягы ас-
тыннан үткән һәр унынчы хайван Раббыныкы. [33] Ул хайван яхшы
булса да, начар булса да, хуҗа аны сайлап һәм алмаштырып то-
рырга тиеш түгел; әгәр кем дә булса аны алмаштыра икән, алмаш-
ка биргән хайван да, алмашып алган хайван да Раббыныкы була;
алар йолым түләп кире алына алмый».
[34] Синай тавында исраиллеләргә Муса аша бирелгән Раббы бое-
рыклары менә шулар.

* 27:30 *Гошер* – керемнең уннан бер өлеше Аллаһыга багышлана торган җыем.